ИСЕМ КУРКЫТМЫЙ

Татар һәм Рус Әҗәле авыллары ничек яши?

> 5

САБАН ТУЕ

Быел бәйрәмдә миллилек артачак

> 15

ҮЗЕБЕЗНЕКЕ ЖИТӘ!

Илдә үзебезнең брендлардан торган 400гә якын яңа кибет ачылырга тиеш

> 17

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 77 (29044) | Җомга | 2 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИЛ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН ГАЗЕТАМ БАР!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»НЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫНА – 105 ЕЛ

«Ватаным Татарстан» газетасының 105 еллыгы, мөгаен, берәүне дә битараф калдырмагандыр, дип уйларга нигез бар, чөнки бу – басманың гына түгел, бөтен татар халкының 105 еллык гомере диган сүз.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Татарстанда социаль ипотека программасы 17 ел гамәлдә. Шул чорда программада катнашучыларның гаиләләрендә 60173 бала дөньяга килгән. Һәрбер балага республика бюджетыннан 200әр мең сум күләмендә субсидия бирелгән. Балалы гаиләләргә ярдәм «Демография» илкүләм проектының төп максатына ирешүгә юнәлдерелгән.

Социаль ипотека программасы буенча исәпкә куелганнан соң туган (яки уллыкка (кызлыкка) алынган) һәрбер балага субсидия бирелә. Аны фатир алу өчен беренчел кертемне арттыру, шулай ук алынган торак өчен бурычның бер өлешен каплау максатында тотарга мөмкин.

3 июнь көнне Әгерҗе районы Пеләмеш авылы янында марийларның «Семык» республика бәйрәме узачак. Анда беренче тапкыр ике төбәк башлыгы: Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Мари Эл башлыгы Юрий Зайцев булачак. Бәйрәм тантанасы 11.30 сәгатьтә ачыла.

Кунакларны бәйрәм боткасы, мари халкының милли аш-сулары белән сыйлаячаклар, этнографик утарлар (районында яшәүче марийларның тарихы, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башындагы милли киемнәрә тәкъдим ителәчәк), милли республикабыз халыкларының көнкүреше белән танышырга мөмкин булачак.

Татарстанда атна ахырына кадәр җылы һава, урыны белән кыска вакытлы яшенле яңгырлар көтелә. Шимбә – 3 июньдә дә яшенле яңгырлар явып үтәчәк. Көндез +23...+28, төнлә +11...+16 градус җылы булачак. Якшәмбе – 4 июньдә дә явым-төшем булырга мөмкин. Көндез һава температурасы +19...+24 градус (көнчыгыш районнарда +29), төнлә +11...+16 градус була дип фаразлана.

Киләсе атна башында – 5–6 июньдә явым-төшем ихтималы аз. Көндез +20...+26, төнлә +5...+11 градус.

Гидрометеоүзәк фаразына караганда, җәйнең беренче аенда Татарстанда айлык уртача һава температурасы нормадан 1 градуска югарырак булачак. Республика өчен июнь ае нормасы +17,8 градус.

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны	Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен	гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~
П2409 атнага дүрт тапкыр чыга	Ташламалы бәя 1051 сум 80 тиен	гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Реклама 16+

ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘРНЕ КАЙГЫРТЫП

КАЗАНДА «ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР» ДӘҮЛӘТ ФОНДЫ ФИЛИАЛЫ АЧЫЛДЫ

Андрей Карабашев махсус хәрби операция зонасында узган елның апреленнән ноябренә кадәр хезмәт итә. Башта «Барс»-та, аннан «Тимер» батальонына кушыла. Хәрби хәрәкәтләр кырында ни-нәрсә җитмәвен дә, андагы һәм аннан кайткан егетләргә ни кирәген дә яхшы белә ул. Махсус хәрби операция ветераны Казанда ачылган «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды филиалында юридик сораулар буенча ярдәмче булып хезмәт итәчәк.

Нинди сорау белән килсәләр дә, җавап табачаклар. Казанда «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды филиалы ачылды. Искәртеп үтик: Россия Президенты Владимир Путин мондый фонд булдыру турындагы Указны бу елның апрель башында чыгарган иде. Фондның Татарстан филиалы инде ачык. Эш башлар алдыннан фонд хезмәткәрләренә хәер-фатиха бирергә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та килде.

– Бу бина хәрби хәрәкәтләр зонасын узган ветераннарның сорауларын хәл итү өчен өстәмә мөмкинлек бирәчәк, – диде республика җитәкчесе. – Аларга һәм гаиләләренә ярдәм итү – безнең эшнең өстенлекле юнәлешләренең берсе. Алда зур һәм җаваплы эш көтә. Бер генә проблема да игътибарсыз калырга тиеш түгел. Без, үз чиратыбызда, киләчәктә дә фонд эшчәнлегенә һәрьяклап ярдәм күрсәтәчәкбез. Бездә Федераль фонд белән дә яхшы элемтәләр урнаштырылган. Без фонд акчасына гына таянып калмыйча, үзебез дә ярдәм күрсәтәчәкбез. Минемчә, бу – вакытында төзелгән һәм бик кирәкле оешма.

Фондның республикадагы бүлеген элек Татарстанда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Конституция суды судьясы булып эшләгән Гүзәл Удачина җитәкли. Яңа вазыйфада үзе өчен яңа бурычлар күрә ул.

– Берәү дә читтә калмасын иде. Һәрбер гаилә, һәрбер ветеран безнең игътибарда булырга һәм аларга каралган ярдәм күрсәтелергә тиеш. Безгә нинди сораулар белән килерләр – әле билгесез. Әмма без әзер булырга тиеш, – диде җитәкче.

«Ватанны саклаучылар» фондында мөрәҗәгать белән килүчеләргә социаль координаторлар – министрлык вәкилләре, психолог, табиблар һәм юристлар ярдәм итәчәк.

– Алар бер ай махсус укулар узды, тест үттеләр. Филиал кысасында Казанда 9 шундый координатор эшли. Ел азагына аларның саны 40ка җитәр дип көтелә, – диде Гүзәл Удачина. Татарстан буенча исә 180 шундый хезмәткәр җәлеп ителәчәк. Алар республиканың 18 районында эшләячәк.

Гүзәл Удачина телгә алган социаль координаторлар – республикада яшәүче гап-гади кешеләр. Йөрәкләре белән ярдәмләшү теләге идарә иткәнгә күрә, әлеге фондка кушыла алар. Шундыйларның берсе – Ольга Ильдукова.

Әңгәмәдәшебез – Әлмәттән. Кызганыч, ире бу елның февралендә махсус хәрби операциядә һәлак булган. Ольга ханым ике бала белән тол кала.

– Ирем минем өчен каһарман иде һәм шундый булачак та. Аны орден белән дә бүләкләделәр, – дип сөйләде Ольга Ильдукова. – Соңгы тапкыр безнең белән 9 февральдә сөйләште. Көнкүрешебез турында, гаилә хакында сорашты. Моңа кадәр ничек яшәдек, шулай яшә, үзеңне бернәрсәдә дә чикләмә, дигән сүзләр әйтте. Еламаска, моңсуланмаска кушты. Үлеме хакында 17 февральдә белдек.

Башка төшкән кайгыдан соң, кәгазь боткасына чумарга да туры килә. «Тегендә барасың, монда керәсең, бер кәгазь урынына икенчесен сорыйлар. Мин моның ни икәнен беләм. Шуңа күрә бу фондның әһәмиятен дә аңлыйм. Апрель аенда Әлмәт башлыгы Тимур Нагуманов белән очраштык. Ул миңа фондта эшләргә тәкъдим итте. Минеке кебек кайгы кичергәннәргә ярдәм итәсем килде. Шуңа ризалаштым да. Мин монда иремнең эшен дәвам итеп эшләргә дип килдем», – диде ул.

Ольга Ильдукова, әлеге фондның әһәмияте бәяләп бетергесез, ди. «Кешеләр бездә өендәге кебек мохитне тоярга, ә без аларга карата кешелекле булырга тиеш. Бу бик мөһим», – дигән фикердә ул.

Махсус хәрби операция ветераны Андрей Карабашев юридик ярдәм күрсәтүгә алыначак. Яралану, госпиталь юлын күргән хәрби социаль координатор булырга карар кылган. «Фонд бик кирәкле. Хәрбиләргә дә, аларның хатыннарына, туганнарына да монда мөрәҗәгать итү бик уңайлы булачак. Барысы да бер җиргә җыелган, барысы да шул темага махсуслашкан. Координаторлар юнәлеш биреп торачак», – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

tatarstan.ru

ФОНД ТУРЫНДА

- Филиал Казанда Ямашев проспекты, 1 адресы буенча ачылды. Төп максаты – махсус операция ветераннарына һәм анда һәлак булган сугышчыларның гаиләләренә шәхси социаль ярдәм күрсәтү, аларга барлык тиешле ярдәм чараларын алуда булышу.
- Филиал дүшәмбедән җомгага кадәр – 9.00дән 18.00 сәгатькәчә, төшке ашсыз эшләячәк.
- Бина 550 квадрат метр мәйданны били.
- Аны 20 көн эчендә сафка бастырганнар.
- Бинада социаль координаторлар кабинетлары, психологик һәм юридик ярдәм төркемнәре, конференцияләр залы һәм башка заллар каралган. Бинаны сафка бастырганда транспорт логистикасын да исәпкә алып сайланган. Сәламәтлеге ягыннан үзенчәлекләре булган кешеләр өчен дә кирәкле шартлар тудырылган.
- Фонд филиаллары илнең 35 төбәгендә ачылды.

ПЕРМЬДӘ УЙЛАШТЫЛАР

Сәнәгатьтә яңа технологияләр, авылны саклап калу һәм үстерү. Идел буе федераль округы субъектларының дәүләт хакимияте Закон чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе утырышында шул хакта фикер алыштылар. Бу чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Идел төбәкләренең парламент вәкилләре фикеренчә, хәзерге шартларда кирәкле продукция җитештерүне тиз арада җайга салып кына калмыйча, галимнәр белән киләчәк турында да уйларга кирәк. Шуңа күрә җитештерүчеләр һәм фән әһелләре бергәләп эшләргә тиеш. Инвестиция мөмкинлекләре һәм кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләренә дә игътибар итәсе бар. Сүз уңаеннан, фәнни-технологик үсеш дәрәҗәсе буенча Татарстан – илнең иң яхшы биш төбәге арасында.

Фәрит Мөхәммәтшин сәнәгатькә яңа технологияләр кертү турында сөйләгәндә, предприятиеләргә дәүләт тарафыннан күрсәтелгән ярдәм мәсьәләсенә аерым тукталды. «Әле беркайчан да федераль үзәкнең төбәкләр икътисадына һәм сәнәгатенә мондый күләмдә ярдәм иткәне юк иде», – диде ул. Сәнәгатьне үстерү һәм аның көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру федераль программасы буенча узган ел Татарстан 77,7 млрд сумга якын акча алган. Республикадагы 50дән артык предприятиегә максатчан субсидияләр бирелгән. «Җитештерү һәм импортны алмаштыру проблемалары белән бергә җитештерелгән продукцияне сату һәм сату базарларын эзләү мәсьәләләре дә – көн кадагында», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Утырышта авыл территорияләрен комплекслы үстерү мәсьәләләре турында да фикер алыштылар. Татарстан әлеге дәүләт программасында иң актив катнашучыларның берсе дип санала. Быел республикадагы авыл җирлекләрен үстерүгә 1,8 млрд сум акча каралган. Шуның 1,3 млрд сумы – федераль бюджеттан. Акча авыл җирлегендә торак төзүгә, территорияләрне төзекләндерүгә, юллар төзүгә, капиталь ремонтлауга, гомуми белем бирү һәм мәдәни учреждениеләр биналарын төзүгә тотыла. «Бүген кабул ителгән карарлар РФ Хөкүмәте адресына җибәреләчәк. Минемчә, һәр субъект, шул исәптән Татарстан да аларны башкарма хакимият органнары белән берлектә караячак. Барлык тәкъдимнәр дә хупланыр дип уйлыйм», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Пермьдә бер көн алдан Идел буе төбәкләрендәге закон чыгару органнары каршындагы Яшьләр парламентлары ассоциациясе утырышында яшьләрне борчыган проблемалар турында да фикер алыштылар. Яшь парламентарийлар әйтүенчә, яшьләр туган ягыннан китмәсен өчен, үзен күрсәтә алу мөмкинлегә, үсеш һәм торак шартлары булырга тиеш.

Фәрит Мөхәммәтшин яшь парламентарийларга авыл яшьләренә аерым игътибар бирергә, төбәкләрдә вазгыятьне өйрәнергә киңәш итте. «Татарстанда 4 миллионнан артык кешенең 1 миллионга якыны авыл җирлегендә яши, – диде ул. – Аларны ни борчый, без кадрларны ничек әзерлибез? Авыл кешесе ярдәмне тойсын өчен, тагын нәрсә эшләргә кирәк? Авылда туып, шәһәрдә белем алган яшьләр туган ягына кайтсын өчен, нинди чара күрергә?» Татарстан парламенты башлыгы фикеренчә, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның рухи байлыгы, мәдәнияте һәм теле нәкъ менә авылда саклана. Фәрит Мөхәммәтшинның тәкъдиме хупланды. Яшьләр белән эшне туктатырга ярамый, диде ул.

tatarstan.ru

КИЛӘЧӘК ХАКЫНА

Балалар саулыгы сагында торган хастаханә, мөмкинлекләре чикле балалар өчен инклюзив үзәк, булачак спортчылар әзерләүче стадион белән танышу, яшьләр белән аралашу... Бөтендөнья балаларны яклау көнендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның эш көндәлеге әнә шундый вакыйгаларга бай булды. Бәйрәм көнендә «Тыныч бакча» дигән рухи комплекска да нигез салынды.

Рөстәм Миңнеханов иң элек мөмкинлекләре чикле балалар һәм аларның ата-аналары өчен эшләп килүче «Барысы да – балалар өчен» инклюзив үзәгендә булды. Биредә балалар өчен уен бүлмәсе, психолог кабинеты, тегү остаханәсе эшли. Проект авторы Алия Гайнанова сүзләренә караганда, бу үзәк, иң беренче чиратта, үзенчәлекле балаларның әниләрен берләштерүе белән әһәмиятле. Алар балаларын белгечләр күзәтүендә калдырып эшли ала. Кирәк икән, биредә аларга психологик һәм юридик ярдәм дә күрсәтәләр. Рөстәм Миңнеханов тегү цехын да карады. Биредә мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен кием тегәләр.

Татарстан Рәисе Казанның Дәрвишләр бистәсендәге 6 нчы балалар шәһәр хастаханәсе филиалының яңа бинасында да булды. Монда барлык шартлар тудырылган. Уен залы, ана һәм бала бүлмәсе, буфеты булган көтеп тору зоналары эшли. Хастаханәгә көненә 180ләп кеше мөрәҗәгать итә. Ул барлык заманча җайланмалар белән җиһазландырылган. Хастаханә базасында тәүлек әйләнәсе эшләүче травматология пункты да ачылган. Рөстәм Миңнеханов кабул итү бүлеген, педиатрия блогын, тар юнәлеш белгечләре кабинетларын, УЗИ һәм ЭКГ кабинетларын, көндезге стационар бинасын карап чыкты.

Рөстәм Миңнеханов Дәрвишләр бистәсендә Балаларны яклау көне уңаеннан уздырылган ишегалды бәйрәмендә дә булды. Аннары «Ракета» стадионында яшь спортчылар уенын карады. Биредә «Күн туп» илкүләм ярышларының шәһәр этабы башланды.

– Республикада спорт үсешенә зур игътибар бирелә. Бу яшьләр – республикабызның киләчәге. Бездә футбол үсештә. Безнең «Рубин» командасы Премьер-лигага әйләнеп кайтты. Барыгызга да уңышлар телим, – диде Рөстәм Миңнеханов, катнашучыларны сәламләп.

Киләчәк дигәннән, бу хакта «Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте белән эшчәнлек буенча республика координация советының киңәйтелгән утырышында да сөйләштеләр. Утырышны Рөстәм Миңнеханов уздырды.

– Дәүләт сәясәтенең төп максаты илнең рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләре нигезендә социаль яктан җаваплы, һәрьяклап үсештә булган шәхес тәрбияләүдән гыйбарәт. Махсус хәрби операция һәм тышкы басым шартларында без үсеп килүче буынны да күздән ычкындырмаска, дошманның аларга дөрес булмаган фикер һәм карашлар сеңдерүенә юл куймаска, үз Ватаныңның чын сакчыларын, ватанпәрвәрләр тәрбияләргә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республикада балаларны яклауга зур игътибар бирелүен дә искәртте ул. Рөстәм Миңнеханов яшьләр сәясәте тармагында Татарстанның тәҗрибәсе зур булуын әйтте.

– Бездә заманча яшьләр инфраструктурасы үсештә, иҗтимагый яшьләр оешмаларына, аларның тәкъдимнәренә теләктәшлек күрсәтелә, дәүләт программалары, шул исәптән «Татарстан яшьләр сәясәтенең 2019–2025 елларга үсеше» программасы тормышка ашырыла, – дип белдерде Рәис.

«Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов үз эшчәнлекләре турында сөйләде.

Быелгы Балаларны яклау көне тагын бер мөһим вакыйга белән истә калачак. Кичә Республика балалар клиник хастаханәсендә «Тыныч бакча» дигән рухи комплекс нигезенә капсула салынды. Тантаналы чарада Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Әлеге комплекста мәчет белән чиркәү урнашачак. Аларны биредә дәваланучы балаларның ата-аналары сораган.

Рөстәм Миңнеханов, әлеге комплекс ике диннең бердәмлек символы булачак, дип саный. «Ниндидер борчуы булганда, кеше җанына тынычлык табар урын эзли. Монда моның өчен барлык шартлар да тудырылачак. Безнең искиткеч табибларыбыз, даруларыбыз бар. Әмма тулысынча терелү өчен, кешегә рух ныклыгы да кирәк. Монда килүчеләр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешсен, «Тыныч бакча» исә җәннәтнең бер кисәгенә әверелсен», – дип белдерде Рәис тантаналы чарада.

АККАН СУ КИРЕ КАЙТА

Татарстанда якын киләчәктә үк елга буйлап сәяхәт итүчеләр саны артып китмәгәе. Республикада, җиң сызганып, су юлын яңартуга керештеләр. Бу максаттан май аенда гына «Татарстан флоты» компаниясе оешу турында билгеле булды. Кичә исә аңа кулланышка ике яңа судно тапшырдылар. Заманча теплоходта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та йөреп карады.

– Бүген Россия тарихында истәлекле вакыйга, – диде Яшел Үзәндәге Горький исемендәге завод төзегән «Метеор 2020» һәм «А-217» судноларын суга төшерү тантанасында Рөстәм Миңнеханов. – Советлар Союзы чорында кораблар булган һәм мена бүген без, мөгаен, шул чордан бирле тәүге тапкыр яңа корабларны суга төшерәбездер. Ә иң мөһиме – алар Татарстанда, Яшел Үзәннең Горький исемендәге суднолар төзү заводында эшләнгән.

Рәис алга таба республикада гамәлдә булган пассажир судноларын яңарту юнәлешендә системалы эш алып барылачагын да әйтте. Соңгы арада гына республикада, су юлының файдалануны арттыру өчен, «Татарстан флоты» суднолар йөртү компаниясе төзелү турында билгеле булды. Оешманың устав капиталы 2 миллиард сум күләмендә республика бюджеты инвестицияләреннән гыйбарәт. Барлык акцияләргә дә Татарстан үзе хуҗа булачак. Республиканың Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, «Татарстан флоты» елга флотын, республиканың туристик мөмкинлекләрен һәм су юлы аша төбәкара пассажирлар ташу күрсәткечләрен үстерү белән шөгыльләнәчәк.

– Транспорт белән тәэмин итү – тормыш сыйфатының бер өлеше, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Без автобуслар һәм электричкалар ярдәмендә пассажирлар ташу өлкәләрендә күп нәрсәгә ирештек, ә менә су транспортына килгәндә, булган кораблар белән генә эшләдек. Бүген заманча ике судноны кулланышка тапшырабыз, бер айдан тагын бер судно суга төшерергә әзер булачак. Шул рәвешле, гамәлдә булган составны тулысынча яңартып бетерергә ниятлибез.

Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген Татарстанда шәһәрара пассажирлар ташу белән ике оешма – «Татфлот» һәм Чаллы компаниясе шөгыльләнә. Алар халыкка социаль әһәмияттәге ун маршрут буенча хезмәт күрсәтә. Бер генә сан: бүген гамәлдә булган судноларның уртача «яше» 50 чигенә җиткән! Шуңа күрә республика җитәкчелегенең бу эшкә алуны гаҗәп тә түгел.

Татарстанда башланган эшнең уңышлы булачагына чарада катнашкан «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» генераль директоры Евгений Дитрих та ышаныч белдерде.

– Бүген илнең суднолар төзелеше тармагы үзебездә төпләнгән заманча проектларга кытлык кичерә. Бу җәһәттән, Татарстанда мондый тәҗрибә бар. Сыекландырылган табигый газ ярдәмендә эшләүче ил күләмендә тәүге пассажир судносын нәкъ менә биредә төзеделәр. Лизинг компаниясе республика белән күптәннән хезмәттәшлек итә. Әлеге хезмәттәшлек суднолар төзелешенең Россия Хөкүмәте тарафыннан расланган программасын тормышка ашырырга да ярдәм итәр, дип ышанабыз. Аның кысасында төрле максатларда хезмәт итәчәк 250дән артык гражданнар судносы төзү каралган, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов, тиз йөрешле «Метеор 2020»гә утырып, Казансу буйлап әйләнеп тә кайтты. Ак төстәге теплоходларны Татарстан флагы һәм милли орнаментлар белән бизәгәннәр. Аны Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев исеме белән атаганнар. Казансу буйлап тәүге сәяхәт унбиш минут чамасы дәвам итте.

Теплоходка «ВТ» хәбәрчесе дә утырды. Моңарчы йөргән «Метеор»лардан аермалы буларак, яңа судноның эче, гомумән дә, очкычныкын хәтерләтә. Һәр урындык артында махсус төшереп куя торган өстәлләргә кадәр бар. Бөтен урыннар да эчке якта. «Метеор» барлыгы 124 пассажирга исәпләнгән. Салкын булса – җылыткыч, эсседә кондиционер да эшли. Шунда ук каһвә, чәй һәм тәм-том да саталар. Бөтен уңайлыклар да бар, кыскасы.

– Безгә йөкләнгән җаваплылыкның ни дәрәҗәдә зур икәнен аңлыйбыз, – ди «Татарстан флоты» генераль директоры Роман Лизалин. Хәтерләсәгез, аның җитәкчелегендәге «Арабелла» теплоходы 2011 елгы фаҗигадә суга батучы «Булгария»дән 79 кешене коткарды. Роман Лизалин сүзләренә караганда, быелгы навигация чорында яңа суднолар туристларны Болгарга һәм Зөя утрау шәһәренә йөртәчәк. «Иң элек судноларны яхшылап сынап карарга кирәк», – дип сөйләде ул. Эшкә тәҗрибәле экипаж ялланачагын да әйтте. Киләсе елга исә социаль юнәлешләр буенча эшли башларга, төбәкара туризмны үстерергә дә ниятлиләр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сан

2022 елгы навигация чорында республикада пассажир агымы **330** мең кеше тәшкил иткән. **2025** елда әлеге күрсәткечне **500** меңгә җиткермәкчеләр.

Әйтеп кенә бактым

Шундый бер халәт

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Маридагы «Кленовая Гора» шифаханәсендә ял итүнең соңгы көне. Ни гаҗәп, Казан әллә ни сагындырмаган. Моны җан тынычлыгы эзләвемнең бер галәмәте дип кабул иттем. Яшь барган саен, ыгы-зыгыдан качасы килә икән ул. «Икән» дип язам, чөнки моңа кадәр бу хакта уйлаганым юк иде әле. Дуслар белән аралашу, шау-шулы компанияләрдә булу, тәмен белеп дигәндәй, бәйрәм итүләр тормышымның аерылгысыз бер өлеше иде.

Күңелемнең тынычлык эзләве мине бераз куркыта да, тормышка гамь бетеп бара, ахрысы, дигән ямьсез уйлар кергәли. Үз-үземә: "Тынычланырга иртәрәк әле сиңа!" – дип әйтеп карыйм. Миндә ике «мин» көрәшә, берсе аның шаулы тормыш яклы, икенчесе – каршы, сукин сын. Мин беренчесе җиңүен телим. Берәр көнем эшсез узса, боегып калам, үз-үземә ачу килә. Күңелсез уйларны куарга, сагыш «богавы»ннан котылырга телим. Кулга каләм алуым да шул омтылышка бәйле. Нидер яза алсам, күңел тынычлана.

Бу язмам белән әллә ни шаккатыра алмамдыр да, әмма гомеремнең билгеле бер чорына объектив бәя бирергә тырышу – үзе үк эш, зур эш дип саныйм. Бу әле – үз-үзем белән көрәшү дә. Чөнки гомер агышына каршы йөзәргә омтылам бит! Җырда җырланганча, «...яшәгән саен яшисе килә».

Бу якты дөньяга гомерлеккә килмәгәнемне дә беләм, шул ук вакытта тумас борын картаясы да килми. «Җитмеш дүрт яшь – яшьмени ул?!» – дип үҗәтләнәм.

Бу шифаханә урман эчендә. Һава чиста. Сайрар кошларның, күршем Мөхәммәтҗан абый әйтмешли, «чуты-кәнисе юк». Әче таңнан күке кычкыра башлый. Аның тавышында мәхәббәт хисләрен сизә башладым. Чөнки алар «ку-ку» дип кычкырып, безгә гомер санамый, ә үзләренә яр эзли икән. Шулай да: «Сана, кәккүк, сана таңнарымны...» – дип, мәгълүм җырны шыңшып куям. Күке кинәт туктап калса, ачу да килә әле, аңа: «Тиле күке син!» – дип кычкырам. Бераз тынычлангач: «Бер башлагансың икән, дәвам ит! Яратмагач – башламыйлар, башлагач – ташламыйлар, җүләркәем минем!» – дип көйләп алам.

Ярый әле мин ярата беләм. Яратып үпкәлим, яратып сүгенәм, яратып шатланам, яратып шаккатам... Гомумән, бар нәрсәне яратып эшләргә яратам. Сез дә шулай итегез!

«Кленовая Гора» шифаханәсе.
Май, 2023 ел

СӨТ ҺӘМ СӘЯСӘТ

Соңгы вакытларда россиякүләм матбугатта да, безнең «Ватаным»да да сөт бәяләре төшүнең авыр нәтиҗәләре турында байтак сөйләнде. Сәнәгать товарларының инфляциясе котыргanda, авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр төшү – социаль катастрофа инде ул, әлбәттә.

Хәзер авылда җиде-сигез һәм хәтта аннан да күбрәк сыер асрап, шуның хисабына көн күргән шәхси хуҗалыклар бар. Бәя төшүең беренче шуларга суга. Болар черки томшыгы кадәр генә субсидия ала һәм күп еллардан бирле күләме катып калган ул ярдәм хәлне бик җиңеләйтми. Зур хуҗалыклар һәм фермерлар да түбән бәядән интегә. Продукциянең бәясе төшү – икътисадка карата акрын хәрәкәткә килүче мина белән бер. Карыйсың, барысы да түзәрлек кебек, көтмәгәндә шартлый да куя. Әйтик, сөткә бәя төшү озак сроклы перспективада хайваннарның баш саны кимү, шуның нәтиҗәсендә ашлык бәясе түбәнәю, төзелеш материалларына һәм авыл хуҗалыгы техникасына ихтыяҗ кимү белән кайтаваз бирә. Икътисадта чылбыр реакциясе барлыкка килә, хәтта корыч кебек, беренче карашка, сөттән ерак торган чималларның да кулланылышы кими. Банк тармагы да читтә кала алмый: түләнмәгән кредитлар саны ишәя.

«Сөт бәясе ни өчен түбәнәя?» дигән сорау үзе бик кызыклы бит әле монда. Шуңа җавап эзли башлауга, без кайбер рәсми саннарның, гафу итегез, бармактан суырылганын белә алабыз. Әлегә кадәр сөткә бәя төшү дип махсус яздым. Чынлыкта, аксымга һәм витаминнарга бай эчемлеккә бәя аз гына да төшмәде. Аңа да, аннан ясалган продуктларга да, киресенчә, артты. Әйдәгез, карыйбыз. Быелның 24 маенда Татарстанда атланмайның бер килосы 671,11 сум торган. Бер ел элек 11 майда ул 642 сум 32 тиен йөргән. Күрәбез: бәя ярыйсы гына өсталгән. Эчә торган сөтнең литры быел уртача 67 сум 77 тиен йөри. Үткән ел 65 сум 28 тиен булган. Эремчек һәм сыр кебек продуктларның рәсми уртача бәясе турында кулымда мәгълүмат юк. Бәяләр шулай ук үскәндер дип кенә фаразлый алабыз. Сөтнең сатып алу бәясе катастрофик рәвештә төшә. Шулкадәр төшә: үткән ел утыз сум булган бәя быел кайбер районнарда 15–16 сумга кадәр түбәнәя, шул түбәнәйгән бәяне дә түләмәүчеләр бар дип ишетеп торабыз.

Без – мокытларда сорау туа: ничек инде кибеттәге бәя үскәндә, җитештерүчедән (сөтнең төп чыгымнарын шул авыл җитештерүчеләре күтәрә) сатып алу бәясе кискен түбәнәя ала? Бу сорауга җавап эзли башлау белән без зур сәеркә кереп китәбез. Иң беренче җавап ук сагайта. Сөт эшкәртүчеләр, аннан сөт продуктлары ясаучылар җитештергән продукцияне сата алмыйлар. Сата алмагач, сөтне озак саклана торган продуктларга әйләндереп саклауга куялар. Мәгълүматны үзәк матбугаттан алам. Коры сөтнең склад запаслары – 240 процентка, сыр продуктларыныкы 65 процентка арткан. Аңлашыла инде: саклауга куйган продукциядән акча керми, саклау чыгымнары гына арта. Ә салымнарны һәм кредитларны түлисе бар. Сөт эшкәртүчеләр үз проблемаларын кем җилкәсенә ыргыта? Авыл җитештерүчеләренекенә, чөнки болар, бердән, шыңшудан башка берни эшли алмый, сауган сөтне озак саклауга куеп булмый, эшкәртеп туңдырып куйсаң да, туңдыргычлар тиз тула.

Хәзер сорауның иң кызык җиренә килеп җитәбез. Ни өчен эшкәртүчеләр сөт продуктларын сатмыйлар? Ихтыяҗ юк чөнки. Ул шуның өчен юк: халык сөт һәм сөт продуктларын куллануны кискен киметә. Менә чагыштырыгыз: 1995 елда (халык тәмам бөлгән һәм фәкыйрьләнгән туксанынчы еллар уртасында) Россиядә җан башына бер елга 254 килограмм сөт һәм сөт продуктлары кулланылган. Шул ук елда австрияләр җан башына 356 килограмм сөт ризыгы ашаган. Саннарны истә калдырдыгызмы? Үткән ел Россиядә җан башына сөт ризыклары куллану 12 процентка кимегән һәм җан башына 165 килограммга калган. Сәламәтлек саклау министрлыгы, елга кеше 340 килограмм сөт ризыклары кулланырга тиеш, ди. Сәламәт яшәү өчен шулай кирәк. Димәк, россияле нормадан ике тапкыр кимрәк сөт ризыклары ашый. Халык диетада утыра дип әйтмәс идем мин. Киресенчә, арзанлы дуңгыз итен ашауны арттырганнар. Бу соңгы ризыкның сәламәтлек өчен файдасы турында уңай сүз әйтеп булмый. Һәрхәлдә, диетик ризыклар исемлегенә керми.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шушы урында без Росстатның: «Россиядә фәкыйрьләр саны кими», – дигән тантаналы хисабын искә төшерә алабыз. Әйе, әйе, фәкыйрьлек чигенең планкасын түбән төшерсәң, хисап өчен матур саннар килеп чыга, әмма отчет белән тамак туйдырып булмый. Туяр-туймас ашаучылар, хәтта каһәрләнгән туксанынчы еллардагыдан да начаррак туклanучылар бар. Юк, авторны капиталистик чынбарлыкны бозып күрсәтүдә гаепләргә ашыкмагыз, ул бары тик рәсми саннардан гына файдалана. Мәсәлән, статистикага карасаң, бездә уртача хезмәт хаклары үсә. Аның үсеш темплары канга бик тоз сала инде салуын. Вәләкин без хезмәт хакларына кагылышлы объективрак башка саннан файдаланабыз. Болай дип фикер йөртәбез. Хезмәт хакыннан бар кеше дә физик затларның салымына керем дигән (НДФЛ) салым түли. Хезмәт хаклары чынлап та үссә, бюджетка кергән шул салымның күләме котылгысыз рәвештә үсәчәк. Финанс министрлыгы дигән оешма яшерми: «2023 елның беренче кварталы нәтиҗәләре буенча НДФЛ керемнәре 20,2 процентка кимеде», – ди. Салымның кимегән тулаем күләме 250 миллиард сум тәшкил итә. Ил буенча шулай, бәлки Татарстанда хәл уңайрактыр. 2023 елның гыйнвар – март айларында бездә физик затларның керменә салым узган елның шул чорының 84,2 процентын тәшкил итә. Россиянекенә караганда хәл яхшырак, әмма барыбер хезмәт хакларыннан җыелган салым Татарстанда да кимегән. Хәзер әйтегез инде: үскәнме хезмәт хаклары? Юк, без бәхәсләшмибез, уртача хезмәт хакы үскәндер дә, бәлки, чөнки кереме миллиард сум булган бер кешенең акчасына уналты мең сумлык хезмәт хаклы меңләгән кешенекен кушып исәпләсәң дә, уртача сан зур чыгачак. Әмма илдәге вазгыятьне ул сан билгели алмый, теге минималь хезмәт хакы алганнарның тамагы уртача хезмәт хакы үскәнгә карап туймый.

Болар турында уйлаганда, без сәясәтнең зур юлына килеп чыгабыз. Санкцияләр безнең икътисадны җимермәде дип фанфаралар кагып була, әмма илдәге матди тормыш дәрәҗәсе шул санкцияләр нәтиҗәсендә начарая. Сөтнең сатып алу бәясе төшүгә дә турыдан-туры катнаша алар. Складларда җыелган теге сөт продуктларын экспортка озатсаң, вазгыятьтән чыгып булыр иде. Әмма белгечләр, кефирны һәм атланмайны читкә озатырга түләүгә бәйле проблемалар комачаулый, диләр. Чит илдәге партнерлар безгә нинди валюта белән түлиләр? Юань беләнме? Юаньны табасы бар әле аның өчен. Тапсаң да, сәүдә итү өчен, Пекин белән килешергә кирәк. Пекинда «ә» дигәнгә «җә» дип торырга ашыкмыйлар. Шуңа күрә «склад запасы» дип аталган теге сөт продуктларын, саклау срогы чыгуга, чүплеккә ташларга да туры килмәгәе.

Россия сөт экспортлый ул экспортлавын, әмма чит илләрдән дә байтак сатып ала. Сатып алынганы читкә сатканга караганда күбрәк. Импортны киметеп, үзебезнең җитештерүчеләргә берникадәр җиңеллек китереп булыр иде. Россельхознадзор вакыты-вакыты белән читтән сөт сатып алуга чикләүләр керткәли, чынлап та. Әмма монда таякны читтән тыш бөгеп җибәреп булмый. Евразия икътисадый союзы дигән оешма бар. Россиядән тыш анда элеккеге дүрт совет республикасы кергән. Килешүләрне бозып, алар белән араны өзеп бетерсәң, тагын кем белән сәүдә итәсең. Болай да ярымблокада хәлендә яшибез бит инде. Кыргызстанда сөтнең тоннасы – 392 доллар, Казахстанда – 402, Беларусьтә 481 доллар тора. Иң кыйммәтле сөт – Россиянеке, тоннасы – 562 доллар. Арзанлы товар кыйммәтле базарларга бәреп керә икән, гаҗәп түгел. Товарларның үзара иреклe әйләнеше турындагы килешү дә бар, аның үтәлүе Россия өчен кирәк.

Мәскәүдә сөт проблемасын хәл итүнең юлларын эзләмиләр түгел, эзлиләр. Эчке базарны киңәйтергә мөмкин. Мөмкин генә түгел, бу – иң отышлы юл. Моның өчен аз керемлеләргә сөт сатып алу өчен карточкалар бирү идеясе күтәрелә. Шәп идея, аны һичшиксез тормышка ашырырга кирәк. Әмма кем финанслый соң, акчаны кайдан алырга? Көнбатыштагы конфликтка бәйле санкцияләр аркасында болай да чыгымнар үсте, керемнәр кимеде. Бердәнбер юл – санкцияләр божрасын өзү. Бу исә – янә сәясәт. Сыерга аңлатып кара син ул сәясәтне...

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӘҖӘЛЕНЕҢ СҮНҮЕМЕ?

Яшел Үзән районында беренче ишетүгә үк атамалары үзенә җәлеп итә торган ике авыл бар. Татар Әҗәле һәм Рус Әҗәле дип атала алар. Безне дә авылларның гадәти булмаган исемнәре һәм бүген халкының ничек көн итүе кызыксындырды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татар Әҗәле

Рус Әҗәле авыл җирлегенә биш авыл (Рус Әҗәле, Татар Әҗәле, Татар Наратлысы, Рус Наратлысы, Карашәм) керә. Аларның барысында бергә 365 кеше теркәлгән, яшәүчеләр аннан да кимрәк. Рус Наратлысында бары биш кенә кеше гомер итә. Билгеле ки, ике авылда да халыкның күпчелеге – өлкәннәр һәм урта буын.

Иң элек без Татар Әҗәленә кердек. Зөя елгасының түбән очына нигезләнгән кечкенә генә матур авылда 30га якын кеше яши. Халкына караганда, җиргә сеңгән, ялгыз, ташландык хәлдә булган йортлары күбрәк шикелле тоелды. Эшкә сәләтле яшьтәгеләрнең күпчелеге «Кызыл Шәрыкъ» комплексында эшли. Авылда терлек асраучылар да бармак белән генә санарлык. Нибары өч сыер калган. Социаль объектлардан да Татар Әҗәләндә иске медпункт кына бар. 1980 нче елгы янгыннан соң клубны да кабат төзеп тормаганнар. Рус Әҗәләндә исә бер бинада авыл советы, китапханә, медпункт һәм почта урнашкан.

– Кызганыч, кеше бик күп үлә. Яше дә, карты да. Авылларда кеше күзгә күренеп кими. Шулай да без, булдыра алганча, халыкка уңайлыклар тудырырга тырышабыз. Яңгыр яуса, юлларыбызда йөрү авыр була торган иде. Үзара салым акчасына аларны җайга сала башладык. Тик халкы аз булгач, акча аз җыела. Шуңа күрә юлга ком-таш салу да авырлык белән бара. Ел саен өч авылда берәр урамга юл салабыз, – диде авыл җирлеге башлыгы Гөлнара Семахина.

Авыл халкы әйтүенчә, ул якларның табигате гөмбә, җиләккә бай. Заманында халкы да бик яратып җыйган, тик хәзер табигать нигъмәтләрен җыеп, кәсеп итүчеләр юк дип аңладык.

– Бер апабыз гөмбә, җиләкне аеруча күп җыя торган, бик тырыш кеше иде. Җыйганны эшкәртеп сата иде. Машинага тага торган арбалары гөмбә белән тулы булыр иде. Бакчасында да күпләп сарымсак үстереп, шуны сатты. Кызганыч, берничә ел элек ул да үлеп китте, – дип искә алды авылдашлары.

Атамасы

Инде авылның атамасына килик. Атамасына бәйле берничә риваять бар. Гөлнара Семахина әйтүенчә, бу җирләргә беренчеләрдән булып абыйлы-энеле ир-атлар килеп урнашкан. Берсе Әҗил исемле булган.

– Авылның дөрес атамасы – Әҗил. Безнең рәсми документларда Татар Әҗиле дип мөһер сугыла. Элмә такталарда да Әҗил дип язылган. Тик шул ук вакытта Әҗәле варианты да бар. Халык теленә ул Әҗәле дип кереп урнашкан. Татар Әҗәле, Рус Әҗәле дигәч, кеше куркып китә. Бервакыт бер танылган җырчының концертына баргач, сәхнәгә менәргә туры килде. «Рус Әҗәленнән килдем», – дигәч, ул: «Кеше куркытып йөрмәгез әле», – дип шаярткан иде.

Татар Әҗәленең иң өлкән кешесе Ризван Мөхтәров сөйләвенчә, авылга Хаҗ Гали дигән кеше нигез салган булырга тиеш. «Безгә кадәр килеп җиткән риваятьләр буенча, ул хаҗга барган кеше булган. Бик авырлык белән килеп җиткәч: «Әҗәлем шунда булыр», – дип әйткән ди. Авылның атасы шуннан килеп чыккан», – дип сөйләде ул.

Билгеле булганча, татар милләтенең күренекле мәгърифәтчесе Каюм Насыйри да – шушы як кешесе. Ул да авылның атамасы турында түбәндәге сүзләр язып калдырган булган: «Бу авыл Әҗәл яки Әҗәле дип аталуның сәбәбе шулдыр: бу авылга иң әүвәл Хаҗ Гали дигән кеше килеп урнашкан икән. Аны кыскартыбрак Аҗәли дип йөрткәннәр. Шуннан Әҗәле булып калгандыр. Ул Хаҗ Гали исемле адәм алты кеше белән Болгардан килеп, авыл булып утырганнар... Бу Әҗәле авылы бик күптән бардыр. Әҗәл зиаратендә бер таш бар, язылганына дүрт йөз елдан артык. Әмма хәзерге Әҗәле элгәреге урыныннан күчеп, икенче җиргәрәк утырган, диләр».

– Рус Әҗәле авылы янында Гөбенә елгасы ага. Аның каршы ягында авыл булган, дип әйтәләр, – дип тә сөйләде Ризван абый. – Аларны су баскан. Рус Әҗәле волость булган булырга тиеш. Тәрләмә якларыннан узучы олы юлда юлбасарлар йөргән. Алар авыл халкына бик зур зыян күрсәткәннәр, җәфа чиктергәннәр. Алардан качып, халык Рус Әҗәленә килеп урнашкан, диләр.

Читтән килүчеләрне, беренче тапкыр ишетүчеләрне сискәндереп җибәрсә дә, халкы авыл атамасына андый зур мәгънә бирми булып чыкты.

– Бу турыда хәтта уйлаганыбыз да юк. Нәрсәсеннән куркасың инде аның? – дип аптырый Миләүшә Мөхтәрова. – Яңа танышларыбыз гына сискәнеп китә. «Шундый исем буламыни?», «Бигрәк ямьсез», – дип әйтүчеләр дә бар.

«Авылым сүрелә»

Әңгәмәдәшебез Ризван абыйның үзенең дә язмышы гыйбрәтле. 42 яшендә тол калып, биш баласын ялгызы гына аякка бастырган әти ул. Сөекле хатыны, балаларының әнисе 38 яшендә каты авырудан вафат була. Әнисез калганда, төпчекләренә 3 кенә яшь була әле. Өч малай, ике кызны аякка бастырышырга Ризван абыйның әнисе, үзенең һәм хатынының туганнары булыша.

– Кабат гаилә кору турында уйларга вакыт та, теләк тә булмады. Балаларны аякка бастырырга кирәк иде, – ди Ризван абый. – Әле ярый әни, туганнар булды. Авыр чакта берсе дә ташламады. Әнисез үсәләр дә, балаларның миңа зарланганы булмады. Аларга да кыен булгандыр, тик сиздермәделәр. Ләкин кәефләре төшсә, ниндидер авырлыклар килеп чыкса, әниләрен юксынып, «әни булса...» дигән сүзләрне әйтәләр иде. Үзем дә, шелтәлисе урында да, тыелып кала белдем. Күңелләре кителмәсен, дип тырыштым.

Сынаулар аннан соң булып тора әле. Башта – мунчалары, шуннан соң йортлары янып көлгә әйләнә. Анысын торгызырга исә халыкның да өлеше шактый керә. Без килгәндә дә хуҗалар шул йорт янында мәш килә иде. Әтиләре өлкән яшьтә булгач, балалары да – гел аның янында. Кызы Миләүшә, шәһәрдәге эшен калдырып, авылга кайтып урнашкан. Сарыклар, сыер һәм бозаулар асрыйлар.

– Элек безнең авылда сарыклар күп иде. Хәзер күпчелек кеше бетерде. Терлекләрдән бозау гына асрыйлар, – ди Миләүшә. – Безнең авыл элек тә зур түгел иде. Еллар узган саен, халкы тагын да кимеде, йортлар бушады. Китәселәре китеп бетте.

Авылның сүнеп баруы Ризван абыйны да бик борчый.

– Мин гомер буе шушы авылда яшәдем, колхозда эшләдем. Авылым күзгә күренеп сүрелеп бара. Берничә елдан бөтенләй бетәчәк, дип уйлыйм. Киләчәге бер дә өметле түгел бит, – дип, күз яшен сөртеп алды ул. – Элек хайван асрарга да иркенрәк, җайлырак иде. Хәзер хайван да асрап булмый, көтүләр дә бетте. Яшьтәшләрем дә калмады диярлек. Әле ярый машина, телефон бар. Туганнар белән аралашып яшибез. Балаларым да ялгызымны гына калдырмый.

Рус Әҗәле

Күршесе Татар Әҗәле кебек үк Урыс Әҗәле дә зур түгел. Бер генә озын урамлы авыл булып чыкты ул. Тик монда яшәүчеләр саны бераз күбрәк: 70 кеше. Гөлнара Семахина әйтүенчә, Рус Әҗәлендә элек бары тик руслар гына яшәгән. Ә хәзер халыкның күпчелеге – татарлар. Авылның клубы да, мәктәбе дә, балалар бакчасы да юк.

– Рус Әҗәлендә урта мәктәп бар иде. Анда үзебезнең авыл советына караган авыл балалары гына түгел, башка күрше-тирә авыллардан да килеп укыйлар иде. Танай авылында ике катлы зур мәктәп төзелгәч, бездә укучылар саны кимеде, шулай итеп, 2009 елда мәктәбебезне яптылар. Хәзер балалар автобус белән Танай авылына йөреп укыйлар. Хәер, соңгы елларда балалар да бик аз туа. Узган ел – бер, быел бер бала туды, – диде җирлек башлыгы.

Әлегә авылда яшәүчеләрнең дә күпчелеге – урта һәм өлкән буын. Яшь гаиләләр, булса да, берничә генә. Авылның төп тоткалары исә – Гүзәл һәм Азат Бикмуллиннар шикелле, аны бөтен барлыгы белән яратучылар. Хуҗабикә үзе социаль хезмәткәр булып эшли. Абзар тутырып мал-туар асрыйлар. Өч сыер савалар, сарыклары, кош-кортлары бар.

– Без гомер буе авылда көн итәбез инде, – дип елмаеп сөйләште безнең белән Гүзәл апа. – Сыер асрауның файдасы юк, диләр. Ләкин без алай дип санамыйбыз. Тырышсаң, табарга була. Терлек тотарга шартлар бар. Малларны йөртә торган Гөбенә елгасы буенда иркенлек, электр көтүче тора. Көндәлек чыгымнарны капларга сөт акчасы җитеп бара. Ай саен акчасын биреп бардылар, тик ел башында тапшырган сөт өчен акчаны әлегә кадәр ала алганыбыз юк. Сөт җыючыга бирмичә, халыкка сатсаң, отышлырак, билгеле. Авылга шәһәрдән кунакка кайтучылар күп, ә мал тотучылар аз. Авылда нибары биш сыер гына калды бит. Менә әле кичә генә бер кеше 1000 сумлык сөт алып китте. Аларга литрын 50 сумнан сатабыз. Ә сөт җыючыга 18 сумнан тапшырабыз. Бәяләр быел бик нык төште бит инде, ләкин аңа карап, без малларны киметергә уйламыйбыз. Әле киресенчә, таналар артырга тора.

Терлек тотар өчен гаилә башлыгы Азат абыйның механизатор булып эшләве бик ярап куя, әлбәттә. Игенен ургач – ашлыгы, үләнен чапкач, печәне кайтып тора, дигәндәй. Шуңа күрә алар авылларының озын гомерле булуын тели.

– Авылны ничек яратмаска мөмкин? – ди Гүзәл апа ихластан. – Без монда 35 ел яшибез. Авыл тормышы эшләгән кешегә бик рәхәт. Аксыйсың-туксыйсың, чабасың-торасың, авасың, торып, тагын чабасың... Менә аякларым да авырта югыйсә, ләкин малны барыбер бетерәсе килми. Ничек ташларга була аларны? Иртүк торып, абзарга чыкмагач, авыл тормышы буламыни инде ул? Шәһәрдә яши алмас идем. Анда баргач та, тизрәк кайту ягын карыйбыз бит без. Кешенең күңел сафлыгы өчен авыл кирәк.

ИЛ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Изге урын

Илебездә «Ватаным Татарстан» кебек озын гомерле басмалар бик аз. Төптәнрәк уйлап карасаң, газета бер гасырдан артык вакытның вакыйгаларын сыйдырган изге урын кебек. Күпьеллык архив, чорның тиңдәшсез һәм кабатланмас документы, Татарстанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең иң тулы һәм төгәл тарихы ул.

105 ел дәвамында газетаның исеме ничек кенә үзгәрмәсен, нигездә, «Татарстан» сүзе һәрвакыт диярлек сакланып килгән. Бу – үзе үк үзенчәлекле тарихи күренеш һәм аның мәгънәсе тирән. Чөнки заманалар да, журналистларның, хезмәткәрләрнең, укучыларның буыннары да алмашынып тора, тормыш-көнкүреш үзгәрә, әмма газетаның алыштыргысыз төп максаты үзгәрми: ул Татарстан халкына, татар халкына хезмәт итә.

«Ватаным Татарстан» – Россия төбәкләре арасында бүген дә иң абруйлы газеталарның берсе, аның ил күләмендә иң зур тиражлы милли басма буларак, Россия матбугатының алтын фондына кертелүе әнә шул хакта сөйли.

Күргәзмә

Юбилей елында эшләнгән һәр гамәл, әйтелгән һәр сүз тарих битләренә кереп калырлык, киләсе буыннарга тапшырырлык булсын дип, быел без юбилей уңаеннан «Ватаным Татарстан» газетасында хезмәт иткән һәм бүген эшли торган журналистларның китапларыннан күргәзмә оештырдык. Монда редакциядә эшләгән язучыларның әдәби китаплары турында гына сүз бармый. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп үтик: тарих битләрендә калсын, югалмасын дип, редакциядә эшләгән язучыларның тулы исемлеген дә булдырдык. Газетабыз гасыр дәвамында татар язучылары өчен затлы мәйдан булып торган. Милләтебезнең мәшһүр уллары Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил каләмнәре бөекләгән мирас итеп алган газета язучыларның әдәби әсәрләрен һәрдаим бастырып килә.

Ә журналистларның китапларына килгәндә исә, аларның күбесе газета битләрендә чыккан язмалардан тупланган, авыл тарихы турында язылганнары да бар. Китап киштәсе янында бу манзараны күзәтү, мөгаен, күп кешедә китаплы булу теләгән дә уяткандыр. Гомерен «Ватаным Татарстан»га хезмәткә багышлаган Илсөяр апа Хәйруллина да бу җәһәттән гаҗәпләнүен яшермәде:

– Мин журналистларның китап чыгару эше белән мавыкканнарын белә идем инде. Бүләк иткәләгәннәре дә бар. Әмма хезмәттәшләремнең бу дәрәҗәдә талантлы икәнлекләренә тагын бер тапкыр сокландым. Искиткеч зур байлык бит бу, – диде ул.

Әйтергә кирәк, Илсөяр апа үзе дә – 40тан артык китапка «җан керткән» кеше. Ә баш мөхәррир урынбасары Габделбәр Ризванов, редакциядә эшләгән 52 елында 60тан артык китапның төзүче-редакторы булган.

Хезмәттәшебез сүзләренә шуны да өстәп әйтик: юбилей үткәрелгән Милли китапханәдә әлеге байлыкның бер өлеше генә куелган иде. Күргәзмә редакциядә урын алачак һәм без аны тулыландыру эше белән алга таба да шөгыльләнәчәкбез.

Күп кеше легендар фотохәбәрчебез Дмитрий Бунтуков төшергән фотосурәтләрне карап та хозурланды. Бу урында, мөгаен, һәркем аның белән бергә үткән юлларны искә төшергәндер. Онытмагансыз, дип рәхмәт сүзләре дә җиткерделәр.

Матур бер бизәк

Тамаша залында кемнәр нинди вазыйфада булуга карамастан, бары тик чын дусларыбыз гына җыелган иде. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, сүзне егетләрчә кыска тотып: «Укучыларыгыз күп булсын, уңышларыгыз мул булсын», – дип, матур теләкләрен теләде. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев исә азрак тарих битләрен актарып алды. «Милләтебез тормышына зур йогынты ясаган газета бу, – диде ул. – Бер яктан рәсми, икенче яктан халыкчан. Бу җиңел генә бирелә торган эш түгел. Ә сез шуны югары сыйфат белән эшлисез. Яңалыклардан курыкмыйсыз, эзләнәсез».

Залда утырган ветераннарга газетаның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова аеруча җылылык белән эндәште. «Газета катлаулы, болганчык елларны да, үсеш вакытларын да үз җилкәсендә кичерде. Шушы чорлар аша басманы безнең кулларга исән-имин тапшыра алганыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә», – диде ул. Бүгенге эш турында да онытмады. «Заман яңадан-яңа таләпләр куя. Җитезлек һәм оперативлык, профессиональлек, яңалыкларга әзер булуыгыз өчен рәхмәт сезгә», – дип, сафта торучы журналистларның да күңелен күтәрде.

Ярдәмнәреннән ташламаган Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка, гамәлгә куючылар – Министрлар Кабинеты белән Дәүләт Советына, «татар матбугатына яңа мөмкинлекләр биргән кеше» дип, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтовка, җитди сәбәпләр белән бәйрәмгә килә алмый калган Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыевага, бәйрәмне күңелле иткән сәхнә әһелләренә дә рәхмәтләрен җиткерде баш мөхәррир.

Районнардан килгән кунакларның да сәхнәгә менеп әйтер сүзләре күп булды. «Булган проблемалардан курыкмыйча, чыгу юлларын эзлисез. Авыл хуҗалыгын яктыртуыгыз бик мөһим. Көрәшчеләр өчен аерым рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Менә инде 60 ел буена Муса Җәлил исемендәге турнирга тугры калып, бернигә карамый үткәреп киләсез. Ул – татар халкының матур бер бизәге бит», – диде Балтач районы Башкарма комитеты җитәкчесе, үзе дә легендар көрәшче Айдар Хәйретдинов. Сәхнәгә менми калучылар да күңелгә сары май булып ятарлык теләкләрен җиткерделәр. «Онытмавыгыз өчен рәхмәттән башка сүзебез юк. Безнең өчен бер очрашу – үзе бер гомер бит», – диде күп еллар корректор булып эшләгән Сания Яруллина. Укучыбыз, хәбәрчебез Гарәфетдин Хисаметдинов та фикерләрен әйтте. «Мин, сезгә килгәнче, язмаларымны берничә газетага биреп караган идем. Җыелы сүз ишетмәдем. «Ватаным Татарстан» үзем өчен буй җитмәслек басма кебек тоелган иде. Киресенчә булып чыкты. Халык белән рәхәтләнеп эшлисез икән. Хәзер инде үзем дә журналистка әйләнеп барам», – диде ул, елмаеп.

ГАЗЕТАМ БАР!

Бүгенге «Ватаным Татарстан»

✓ **15** меңнән артык тираж; **41** хезмәткәр; **1** атнага – **4** сан, **32** бит; **1** елга – **200** сан, **1600** бит.

✓ Барлык информацион мәйданнарны исәпкә алганда, бер көнгә «Ватаным Татарстан» газетасында чыккан мәгълүматны **200** мең кеше укый.

✓ Юбилей үткәрелгән **31** май көнне газетаның **29043** нче саны әзерләнде.

Үтемле сүз

Көн саен, сәгать саен, минут саен безнең өскә мәгълүмат ягъгыры ява... Тамчылардан күлләр, елгалар җыела һәм зур бер ташкынга әверелә. Ул ташкында саннар, сүзләр, китаплар, газета-журналлар, радио-хәбәрләр, телевидение тапшырулары, блоглар, социаль челтәрләр, интернет сәхифәләре йөзә... Шул агымнан үзеңә кирәк мәгълүматны аралап алу бер дә җиңел түгел. Кайсы дөрес? Ә кайсында сине ялган көтә? Ничек алданмаска, адашмаска?

Бәйрәмдә бер гаилә тарихы сурәтләнгән сценарийда (авторы – Резеда Гобәева, режиссеры – Лилия Әхмәтова) тамашачылар әнә шул сорауларга җавап эзләде. Җәмил бабай, әтисе эшен дәвам иттереп, «Ватаным Татарстан» газетасын җыеп барган. Тик өйдәгеләр аның сәер гадәтен аңламый. Интернет дөньясында яшәүче оныгы Әмир газета-журналлар җыюның мәгънәсен күрми. Бар әйберне интернеттан табып була дип уйлый. Үз сүзләрен исбатлау өчен, ул бабасына «Ватаным Татарстан»ның интернеттагы рәсми сайтын да табып бирә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: быелгы «Бәллүр каләм» конкурсында «Ватаным Татарстан» газетасы «Мультимедиалы редакция» номинациясендә җиңү яулады. Безнең белән Әмир тапкан сайттан гына түгел, ә бәлки «ВКонтакте», «Одноклассники», «Telegram» кебек башка социаль челтәрләрдә дә аралашырга була.

Җәмил карт боларны белеп бетерми, әлбәттә. Әмма бермәлгә югалып калган төсле булса да, тиз аңына килә ул. «Алай мәгънәсе юк дип кырт кисәргә ашыкма әле, улым, – ди. – Газета, һәр кешенең өенә барып җиткәнче, бик озын юл үтә. Анда күпме кешенең хезмәте, тырышлыгы кергән. Синең бит ул интернет дигән әйбереңне тотып карап булмый. Ут сүнәргә, компьютер ватылырга, интернет юкка чыгарга мөмкин. Бер кнопкага басып, андагы язганны сызып та ташларга була. Ә басылып чыгып, ил буйлап таралган мәгълүматны сызып ата алмыйсың. Аның бит исе дә – дәва. Кыштыр-кыштыр китереп ача-ача, кулга тотып, рәхәтләнеп гәҗит укуга ни җитә!»

Бабай хәйләкәр. Үзенекенә ирешә. Тормыш тәҗрибәсе җитеп ашкан чөнки. Газета ярдәме белән оныгы тарихтан «5ле» дә алып кайта, дус егете Саматка мәхәббәтен табарга да ярдәм итә. Менә шул хәлләрдән соң егет фикерен үзгәртә дә инде. Аның баскычка утырып сөйләгән монологы һәр кешене уйланырга мәҗбүр итте. Залда тынлык урнашты. «...Бабайның газеталарын мин ничектер ярата башладым. Ул әйткән, борынны кытыклап торган исерткеч рәхәт исен дә тоям. Кыштыр-кыштыр китереп, аларны актарудан тәм табам. Сүзнең кәгазьгә язылуы никадәр мөһим икәнлегенә төшендем сыман! Газеталар, китаплар бит – безнең милләтнең дөньяда барлыгын, тере икәнлеген күрсәтеп торучы байлык. Бабай дөрес әйтә. Интернеттан теләсә нәрсәне сызып атырга, төзәтергә була, ә кәгазьдән – юк. Шуңа да алар яшәргә, үсәргә, булырга тиеш. Минем карт бабай да, бабай да юкка гына җыймаганнар бу газеталарны. Милләт тарихын, ил тарихын саклап калу өчен җыйганнар. Мин аларның эшен дәвам иттерергә булдым. Милләтемнең рухи байлыгын минем дә булачак балаларыма, оныкларыма тапшырасым килә. Менә бу – үзем языылып алдырган беренче газета. Бүген минем ил тарихы белән бәйләнгән үз тарихым башлана. Ватаныма мәхәббәт белән сугарылган тарихым!..»

Килешәсездер, «Ватаным Татарстан» турында моннан да үтемлерәк әйтү мөмкин түгелдер.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

РӘХМӘТ

Юбилей чараларын үткәрергә татар матбугатына битараф булмаган егетләребез ярдәм итте. Менә алар:

Фәрдиев Илшат Шәех улы – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры;

Салихов Ирек Фәрит улы – «Ядран» компанияләре төркеме Директорлар советы рәисе;

Кашапов Рамил Әсфәндияр улы – «СМП БАНК» акционерлык җәмгыятенең Татарстандагы филиалы җитәкчесе;

Шәйхетдинов Рәис Тәбрис улы – Биектау сөт комбинаты милектәше һәм генераль директоры.

Редакция исеменнән аларга зур рәхмәтләребезне юллыйбыз.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Юбилей уңаеннан редакция хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә дә ия булды.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте белдерелде.

Бүлек мөдире **Фәния Әхмәтҗанова**га – «Фидакарь хезмәт өчен» медале, баш мөхәррир урынбасары **Габделбәр Ризванов**ка «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тапшырылды.

Корректор **Рәзинә Сәлахиева**га, бүлек мөхәррире **Зөһрә Садыйкова**га, веб-редактор **Гөлнара Гыйниятуллина**га Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Рәхмәте белдерелде.

Корректор **Фәния Фәизова,** фотокорреспондент **Илдар Мөхәммәтҗанов** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Веб-редактор **Лиана Мәрданова** «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.



Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ, Анна АРАХАМИЯ, «Татар-информ» фотолары

5 июнь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.30 «Татарстан без коррупции» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Ильгиз Ханов 16+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Каравай» 6+
01.15 «Вечерняя игра» (2017) 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Җилдергән җитез җилләрдә». И. Хәйруллин турында телеочерк 16+
15.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00, 19.10 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
22.15, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Михаил Гаврилов, Сергей Пускепалис, Агния Дитковските. «ТРЕЙДЕР» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ» 12+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ 2» 16+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20, 02.00 «Легендарные клубы» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 16.50, 19.50 Новости
07.05, 19.00, 21.30, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Спецрепортаж 12+
10.25, 23.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Лучшие голы сезона 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Конор МакГрегор против Нейта Диаса. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «География спорта. Грозный» 12+
15.25 «Громко». Прямой эфир
16.55 «Леннокс Льюис: Нерассказанная история». Документальный фильм 12+
19.55 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
22.15 Футбол. Первая ежегодная премия Российской Премьер-Лиги Winline Герои РПЛ. Трансляция из Москвы 0+
01.25 «Наши иностранцы» 12+
01.55 Новости 0+
03.00 Академическая гребля. Большая московская регата 0+
04.10 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур. Трансляция из Нидерландов 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.45 Премьера. «Путь бойца» 18+
02.45 Илья Шакунов, Алёна Бабенко. «БЕЗДНА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Сообщающиеся сосуды» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «БЕГИ, НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ!» 16+
19.00 «СВАДЬБЫ И РАЗВОДЫ». 1-я – 3-я серии 16+
22.10 «САДОВНИЦА» 16+
01.55 «Понять. Простить» 16+
02.50 «Порча» 16+
03.15 «Знахарка» 16+
03.40 «Верну любимого» 16+
04.05 «Голоса ушедших душ» 16+
04.30 «6 кадров» 16+
04.40 «Тест на отцовство» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.10 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Олег Кулабухов 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.30 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал (СССР, 1988). «Соленый ветер». 1-я серия 12+
12.30, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 15.05 «СОБР». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Новороссия». Документальный сериал. «Новороссия. Дороги слез Дикого поля». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Укронацисты. Добровольные помощники вермахта» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.30 «ВА-БАНК» 16+
02.35 «Перемышль. Подвиг на границе». Документальный фильм 12+
03.30 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+
03.40 «СОБР». 1-я и 2-я серии 16+

6 июнь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (с субтитрами) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Ансамбль песни и танца Республики Адыгея «Исламей» 6+
00.50 «Соотечественники». Кибитка Пушкина 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Вечерняя игра» 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05 «Ком сәгате» 16+
15.25 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Җырлыйк әле!» 12+
19.10 «Музыкаль мәйдан» 16+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Ком сәгате» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ТРЕЙДЕР» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ПАРОМЩИЦА. ДОЛИНА МЕЧТЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ 2» 16+
03.55 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20, 02.00 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «География спорта. Грозный» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 16.50, 21.35 Новости
07.05, 15.25, 21.40, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Мировой футбол. Обзор 0+
11.25 Профессиональный бокс. А. Поветкин – М. Чарр. Трансляция из Москвы 16+
12.15 Профессиональный бокс. Руслан Проводников против Хосе Луиса Кастильо. Трансляция из Москвы 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «География спорта. Оренбург» 12+
16.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. Финал 4-х. 1/2 финала. «СКА Минск» (Белоруссия) – «Чеховские медведи» (Россия). Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
18.35 «Неделя лёгкой атлетики». Прямая трансляция из Москвы
20.30 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. Финал 4-х. 1/2 финала. «Пермские медведи» (Россия) – «Мешков Брест» (Белоруссия). Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
22.25 «Леннокс Льюис: Нерассказанная история». Документальный фильм 12+
01.25 «Голевая неделя. РФ» 0+
01.55 Новости 0+
03.00 Академическая гребля. Большая московская регата 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ВОЕННАЯ ПОЛИЦИЯ» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.45 Премьера. «Путь бойца» 18+
03.05 Детективный сериал «БЕЗДНА» (S) 16+
04.40 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.40 «Давай разведёмся!» 16+
08.40 «Тест на отцовство» 16+
10.50 «Понять. Простить» 16+
12.05 «Порча». «Слепой рок» 16+
12.35 «Знахарка» 16+
13.10 «Верну любимого» 16+
13.45 «Голоса ушедших душ» 16+
14.20 «ВЫШЕЛ ЁЖИК ИЗ ТУМАНА...» 16+
19.00 «СВАДЬБЫ И РАЗВОДЫ». 4-я – 6-я серии 16+
22.20 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
02.10 «Понять. Простить» 16+
03.05 «Порча» 16+
03.30 «Знахарка» 16+
03.55 «Верну любимого» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СОБР». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.20 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Соленый ветер». 2-я серия 12+
12.30, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 15.10 «СОБР». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Новороссия». Документальный сериал. «Новороссия. От Таганрога до Новой Сербии». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.30 «ВА-БАНК 2, ИЛИ ОТВЕТНЫЙ УДАР» 16+
02.25 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
03.50 «СОБР». 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең төзелеш проектларын тормышка ашыру идарәсе төзелешне оештыру хезмәте бүлеге җитәкчесе **Садыйков** Хәмит Сәгыйт улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге һәм квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе факультетының фәнни җитәкчесе **Тарханов** Илдар Абдулхак улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

***

2022/2023 еллар сезоны Континенталь хоккей лигасы чемпионаты – ир-ат командалары арасында хоккей буенча Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерция предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс» хоккей командасы техник директоры **Смирнов** Игорь Николаевич **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

2022/2023 еллар сезоны Континенталь хоккей лигасы чемпионаты – ир-ат командалары арасында хоккей буенча Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә мөһим өлеш кертүе өчен «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерция предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс» хоккей командасы тренеры **Абрамов** Сергей Михайлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

2022/2023 еллар сезоны Континенталь хоккей лигасы чемпионаты – ир-ат командалары арасында хоккей буенча Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерция предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс» хоккей командасы табибы **Ерофеев** Николай Николаевич; торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Каздорсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш энергетигы **Бабичев** Евгений Федорович, Казан шәһәренең «Шәһәрне төзекләндерү» муниципаль унитар предприятиесенең хезмәтне саклау буенча баш белгече – граждан оборонасы буенча белгече **Кашафутдинов** Мансур Мухаметдин улы; массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең телевидение махсус телеоператоры-постановщигы **Кузьмин** Сергей Григорьевич Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

2022/2023 еллар сезоны Континенталь хоккей лигасы чемпионаты – ир-ат командалары арасында хоккей буенча Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерция предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: «Ак Барс» хоккей командасы баш тренеры **Билалетдинов** Зиннәтулла Хәйдәр улы, «Ак Барс» хоккей командасы генераль менеджеры **Вәлиуллин** Марат Фәрит улы, «Ак Барс» хоккей командасы өлкән администраторы **Васькевич** Станислав Викторович, директорның икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Габидуллин** Илнур Имамзөфәр улы, офис-менеджер **Марышева** Ольга Геннадьевна, директор урынбасары **Прудников** Станислав Александрович, медиа-үзәк җитәкчесе **Степанов** Михаил Владимирович; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен фоторәссам, «Иҗат берлеге – Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Гобәев** Фәрит Сәет улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе акционер җәмгыятенең «ШАЯН ТВ» телеканалы дубляж студиясе мөдире Әдиятуллина Роза Рәшит кызына, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиллеге матбугат секретаре **Галәүтдинова** Динә Зиннур кызына, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» филиалының «Татар-информ» татар редакциясе, «Интертат» электрон газетасы, «Атна вакыйгалары» газетасы баш мөхәррире – массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге башлыгы **Латыйпов** Рәмис Нурмөхәммәт улына, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең бүлек мөхәррире **Мифтахова** Сәрия Рәис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе җитәкчесе урынбасары **Арсланов** Рөстәм Әсхәт улы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы **Бочкарев** Дмитрий Валерьевич, хезмәт ветераны **Гиниатуллина** Гөлнур Кыям кызы, «Телекоммуникацияләр 21» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры **Закиров** Зариф Гали улы, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге беркетмә секторы I категорияле белгече **Идиятова** Илсөя Мөхәммәтҗан кызы, Перспективалы тикшеренүләр фонды проект җитәкчесе **Ихсанов** Иршат Айрат улы, хезмәт ветераны **Мингалиева** Тәнзилә Госман кызы, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар «Әллүки» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең музыкаль җитәкчесе **Сафина** Римма Мөхәммәтнәҗип кызы, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Эзмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих укытучысы **Сөләйманова** Наилә Мансур кызы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе редакцион-лингвистик экспертиза бүлеге мөдире **Хәсәнова** Зәнфирә Васил кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел»** медале белән бүләкләнде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧАМАСЫН БЕЛЕП КЕНӘ

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, ил халкының 70 проценты йодка кытлык кичерә. Кеше көненә кимендә 100 мкг йод кулланырга тиеш, ди белгечләр. Бездә исә аның көнлек нормасы 40–80 мкг арасында гына тирбәлә. Организмга йод җитмәү нәрсәсе белән куркыныч? Аның нормадан артып китүе нигә китерә?

КФУ Университет клиникасының табиб-эндокринологы Ләйсән ЗАРИПОВА мәсьәләгә ачыклык кертте.

:: Организмда йодка кытлык ни сәбәпле барлыкка килә?

– Без йодка кытлык зур булган төбәктә яшибез. Аңа кытлык, нигездә, туфрактагы йод күләме аз булу аркасында пәйда була. Туфракта җитешмәгәч, анда үскән үсемлекләрдә, бөртекле культураларда да аның күләме аз була. Диета тоту белән мавыккан кешеләрнең организмына да еш кына йод җитми. Гипертониядән интеккән кешеләргә көн дәвамында ашалган тоз күләмен чикләргә кушалар. Бу исә, үз чиратында, шулай ук йодка кытлык китереп чыгара. Ник дигәндә, тоз – иң төп йод чыганакларының берсе.

:: Йодка кытлык кичергәндә, нинди билгеләр күзәтелә?

– Йод безнең организмга бик кирәк. Ул җитмәгәндә, кешедә билгеле бер чирләр дә килеп чыгарга мөмкин. Йод иң беренче чиратта калкансыман биз көйле эшләсен өчен кирәк. Шуңа күрә организмга әлеге матдә җитмәгәндә, кешедә иң беренче чиратта калкансыман биз авырулары пәйда була. Бигрәк тә гипотериоз очраклары еш очрый. Ул кешенең акыл сәләтенә зыян сала, матдәләр алмашын боза, психикасына тискәре йогынты ясый. Кеше чәч коелудан, тән тиресе бозылудан, эч катудан интегә, күңел төшенкелегенә бирелә. Баланың үсеше дә тоткарланырга мөмкин. Организмга йод җитмәү нәселсезлеккә дә китерә. Шулай ук йод яман шешне дә кисәтә.

:: Организмда йодның нормадан артып китүе нәрсәсе белән куркыныч?

– Йодның җитмәве генә түгел, аның артып китүе дә калкансыман биз авыруларына китерә ала. Йодның артып китүе арасында, иң беренче булып, калкансыман биз зураерга (зоб башланырга) мөмкин.

:: Йод җитмәүне башка чирләрдән ничек аерырга?

– Калкансыман биз белән йод – аерылгысыз төшенчәләр, дигән ышану яши. Чынлыкта аның 2/3 өлеше генә шунда туплана. Йодның калган өлеше төкерек, күкрәк бизләрендә, ашказанының лайлалы тышчасында, йөкле хатыннарның плацентасында саклана. Организмга йод җитешмәгәндә, шул әгъзалар авырулары да пәйда була. Сүз уңаеннан, күкрәк сөтендә йод күләме калкансыман биз тукымаларындагы белән чагыштырганда дүрт тапкыр күбрәк! Калкансыман биз авырулары белән күкрәк яман шеше билгеләре охшаш.

:: Кытлык булмасын өчен, ничек тукланырга кирәк?

– Моның өчен, иң беренче чиратта, ашарга әзерләгәндә составында йод булган тоз кулланырга кирәк. Диңгез тозы, креветка, балык кебек диңгез ризыкларына да өстенлек бирегез. Алар диңгез суындагы йодны үзләренә сеңдерә.

:: Тоз составындагы йод озак сакланмый, ашарга әзерләгәндә очып бетә, дигән фикер яши. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Йод, дөрестән дә, очучан. Азык-төлекне термик эшкәрткәндә бик тиз югала ул. Төгәлрәк әйтсәк, ашарга пешергәндә салынган тоздагы йодның 80 проценты очып бетә. Шуңа күрә аны ризыкка пешеп чыгар алдыннан гына салу хәерле. Тозны дөрес итеп сакларга да кирәк. Ул ябык савытта торырга тиеш.

:: Тукланудан тыш, йодка кытлыкны ниндидер дарулар эчеп тә булдырмый калырга мөмкинме?

– Әйе, бигрәк тә йөкле, бала имезүче хатын-кызларга, балаларга йод запасын шул рәвешле тулыландырырга киңәш ителә. Бүген сатуда организмны йодка баетучы махсус дарулар да, әлеге матдәгә бай үсемлекләрдән ясалган препаратлар да бар. Дөрес соңгыларында йод күләме стандарт белән билгеләнми. Нәтиҗәдә алар аша организмга күпме йод эләккәнен дә чамалап бетерергә мөмкин түгел. Шуңа күрә аларны эчкәндә бик сак булырга кирәк.



vk.com

ЙОД ҖИТМӘҮНЕ ТИКШЕРҮ ЫСУЛЛАРЫ

БЕРЕНЧЕ ЫСУЛ. Кич йокларга ятар алдыннан мамыклы таякчыкны йодның спирттагы эремәсенә манып, тәнгә 10х10 см үлчәмдә челтәр ясарга. Аны муенга, йөрәк тирәсенә сөртергә ярамый. 10–12 сәгатьтән тикшерәбез. Әгәр тиредә рәсем сакланган икән, бар да тәртиптә, сезгә йод җитә. Рәсемнең бөтенләй югалуы әлеге микроэлементка ихтыяҗ булуны сиздертә.

ИКЕНЧЕ ЫСУЛ. Йокларга ятар алдыннан беләзеккә йодлы таякчык белән өч сызык сызалар. Аның беренчесе – 1–2 мм, уртадагысы – 3 мм, өченчесе 5–6 мм киңлектә булырга тиеш. Иртән бу сызыкларны тикшерәләр. Нечкә сызыкның югалуы, калганнарының нык беленеп торуы – йодның җитәрлек булу билгесе. Нечкә һәм уртача киңлектәге сызыклар югалса, көндәлек рационны үзгәртергә кирәк. Күбрәк диңгез ризыклары, балык ашарга тырышыгыз. Сызыклар күренмәү йодка ихтыяҗ зур булуны белгертә. Табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Йодлы рәсемнәрне кичтән, йокларга ятар алдыннан ясагыз. Моны көндез эшләсәгез, урамга, җилгә чыкмагыз.

Саклап куй!

ПИГМЕНТЛЫ ТАПЛАРДАН БИТЛЕК

15–20 грамм чи чүпрәгә 1,5 чәй кашыгы яңа сыгылган лимон согы кушарга кирәк.

Шуны биткә сөртеп, 20 минут тотарга, аннары җылы су белән юып төшерергә. Соңрак биткә тукландыра торган крем сөртегез. Бер-ике атнадан пигментлы тапларның шактый кимегәнлеген күрерсез.

Файдалы

Күзләр өчен салат

Күз күрүе начарланмасын өчен, компьютерда эшләгәндә сәгать саен унар минут тәнәфес ясарга кирәк. Күзләргә түбәндәге салат та файдалы. 1әр өлеш угычтан уылган кишер, вакланган күрәгә, әфлисунга 1 аш кашыгы бал кушып болгатырга. Шуны 10 минуттан ашарга кирәк. Салатны бер ай дәвамында көн дә ашасагыз, нәтиҗәсе озак көттермәс.

Горчица тамак авыртудан коткара

Тамак авыртканда, бер чәй кашыгы тозга бераз гына лимон согы, бер чәй кашыгы бал, ярты чәй кашыгы горчица һәм 100 мл җылы су салабыз. Шуның белән көнгә берничә тапкыр тамакны чайкатабыз. Гайморит булганда, томау төшкәндә, тукыма кисәген кайнар суга манып алып, аңа коры горчица салабыз да борынга куеп торабыз.

Киңәш-табыш

АЯКЛАР ТИРЛӘСӘ...

Моның өчен һәр көнне кич белән аякларны 10–15 минутка шалфей төнәтмәсе һәм аш тозы (ярты табак җылы суга бер уч тоз) кушылган суга тыгып утырырга кирәк. Бу ысул аяк тиресен чистартып кына калмыйча, аны тынычландырырга һәм дезинфекцияләргә дә ярдәм итәчәк. Сүз уңаеннан, тән тиресенә экология генә түгел, ә эче ризыкларны артык күп ашау, җитәрлек дәрәҗәдә сыеклык кулланмау (көн дәвамында тиешле норма – 1,5–2 литр), каты су, селтеле сабын белән юыну, тәмәке тарту һәм аракы эчү кебек начар гадәтләр дә йогынты ясарга мөмкин.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ҮССЕН КЫЯР...

Ямь-яшел кыяр «бәби»ләренең кинәт кенә күзгә күренеп саргаюы – әлбәттә, күңелне төшерә торган күренеш. Соң, безне илһамландырып торган һәм инде хыялда банкага да маринадлап куелган кыярчыкларның кинәт кенә коела башлавы турында ич сүз. Бу хәлне ничек булдырмаска?

vk.com

Бакчачы блогер Людмила КУДРЯВЦЕВА безгә шул хакта аңлатып үтте.

Яктылык җитми

Кыяр – яктылык яратучы үсемлек. Саргаюның төп сәбәбе дә – шул яктылык җитмәү. Ә яктылыкның аз төшүе безнең комсызлыкка да бәйле: имеш, уңышын күбрәк алачакбыз, дип куе утыртабыз... Урынны экономияләмичә, сирәгрәк утыртырга тырышыгыз. Кыяр үсентеләре арасы кимендә 40 см булырга тиеш.

Күп җимшәнле

Кыярларның бик күп яралуы да әйбәт түгел. Әйтик, бер сабакта бер үк вакытта 20–30 кыяр «бәби»е барлыкка килә икән, аларның күбесе саргаеп коелырга мөмкин. Шуның кадәр кыярны өлгертергә үсентенең хәленнән килми чөнки. Шуңа күрә аларның санын киметергә кирәк. Иң элек төп сабакның аскы өлешендә иң беренче пәйда булган җимшәннәрне өзеп алу дөрес булачак. Юкса үсенте бөтен көчен шушы тәүге кыярларны үстерүгә биреп, начар үсә башлаячак һәм кыяр начар яралачак. Икенчедән, үсентенең ян ботакларын кисеп алырга мөмкин. Бу очракта төп ботактагы җимшәннәр коелмаячак – үсентенең кыярларны үстереп җиткерергә көче җитәчәк.

Мин үзем болай эшлим. Төп сабакны калдырып, ян сабагын, беренче яки икенче яфрагы чыккач, кыскартам. Һәрбер яфракта өстәмә рәвештә кимендә берәр кыяр пәйда була. Аларны җыеп алгач, ян ботакны тулысынча кисеп ташлыйм.

Температура килешми

Җәй салкын килсә, ачык туфракта кыяр уңышы бөтенләй дә булмаска мөмкин. Һава температурасы берничә көн рәттән +16 градустан кимрәк торса, җимшәннәре коела башлавын көт тә тор! Шуннан үсентеләр үсүдән туктап, төрле авыруларга бирешә башлаячак. Теплицадагы кыярларга исә, киресенчә, артык эсселекнең зыян салуы бар. Һава температурасы +32 градустан югарырак күтәрелсә, серкәләнү тукталачак. Нәтиҗәдә кыяр җимшәннәре саргаеп коелачак.

Тукландыру кирәк

Мөһим микроэлементлар җитешмәгәндә, яфракларында сары таплар барлыкка килеп, үсенте кыярланмаячак. Бу очракта кичекмәстән тукландырырга кирәк. Кыярлана башлагач, үсенте бигрәк тә фосфор һәм калийга кытлык кичерә башлый.

Суны дөрес сип

Кыярлана башлаганчы, үсенте дымга әллә ни зур мохтаҗлык кичерми әле. Ә менә кыяр ярала башлагач, суны вакытында сибү бик кирәк. Үсентеләргә бары тик җылы яки бераз гына салкынча су сибәләр. Кояшлы эссе көннәрдә – иртән, ә салкынча көннәрдә – көндез.

Тәмле булсын!

Редискадан җәйге салат

Гүзәл ШӘРӘФЕТДИНОВА рецепты

«Заправка»сы бик үзенчәлекле. Шуңа салат искиткеч тәмле килеп чыга.

Кирәк булачак: *уртача зурлыктагы 3 бәрәңге, 8–10 редис, 1 кыяр, 1 помидор, 1 бәйләм (кечерәк) суган кыягы, тәменчә тоз, борыч.*

«Заправка» өчен: *3 аш кашыгы зәйтүн мае, 2 аш кашыгы лимон согы, 1 аш кашыгы горчица, 1 аш кашыгы бал.*

Бәрәңгене, кабыгын әрчемичә, фольгага төреп пешерәбез. Суынгач, кечерәк кисәкләргә турыйбыз. Кыяр, редис (икесенең дә кабыгын әрчергә мөмкин) һәм помидорны – кисәкләп, суган кыягын ваклап турыйбыз. Барысын да тирән эчле савытка салып, тәменчә тоз һәм борыч өстибез. Саклык белән генә болгатабыз.

«Заправка» өчен кирәкле ингредиентларны аерым савытка салып, кашык яки венчик белән күпертәбез. Салатка салып, барысын бергә болгатабыз. Яшелчәләрнең тәме чыксын өчен бераз тотабыз һәм табынга куябыз.

Укучы киңәше

БОТАКТАН ҮРЧЕТӘМ

Кыяр үсентеләрен ачык туфракка утыртырга вакыт җитте. Тәрәзә төбендә урын аз булганлыктан, берничә төп кыяр утыртам да, шуларны үстереп, ботакларыннан үрчетәм мин. Эш тәртибем болайрак. Үсентеләр үскәч, утыртырга берәр атна кала, берничә ботагын кисеп алам да сулы банкага утыртып куям. Калын гына ак тамырлары барлыкка килеп, бераз үскәч, урамга яки теплицага күчереп утыртам. Кыярның тамырлары бик тиз сынучан, шуңа күрә саклык белән генә эш итәргә кирәк. Шулай итеп, бер үсентедән ике яки өч төп кыяр үстерәм.

Римма ҖАМАЛИЕВА.
Чирмешән районы

Исеңдә тот!

ЙОМЫРКА ПОРОШОГЫ ЗЫЯНЛЫМЫ?

Теге яки бу ризык составында йомырка порошогын күрсәк, бернинди дә табигый әйбер калмады инде хәзер, дип зарланырга яратабыз. Гадәти сөт урынына – коры сөт, терлек мае урынына – пальма мае... Инде килеп, тавык йомыркасы урынына – йомырка порошогы... Чыннан да, аннан зарланырга һәм сагаерга кирәкме?

Белгечләр әйтүенчә, йомырка порошогы – «химия» түгел. Табигый йомырканы киптереп ясала ул. Составы ягыннан гадәтиеннән калышмый. Файдалы үзенчәлекләрен дә югалтмый. Өстәвенә, киптергәндә, йомыркадагы барлык бактерияләр юкка чыга. Шуңа күрә аннан сальмонеллез йоктыру куркынычы юк. Шул ук вакытта бик экономияле дә: 100 грамм порошок сигез эре йомырканы алыштыра.

ЗЫЯНЫ. Гадәтиендәге кебек үк, составында «начар» холестерин байтак. Шуңа күрә йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүчеләргә саклык белән генә куллану киңәш ителә. Бавыры авырткан кешеләргә дә кагыла бу.

НИЧЕК САЙЛАРГА? Йомырка порошогы теләсә кайсы кибеттә сатыла. Ул бернинди төерчекләрсез, коп-коры булырга тиеш. Коңгырттрак төскә кереп, көйгәнрәк ис килсә, җитештерү технологиясе бозылган, дигән сүз. Мондый порошокны алмавың хәерлерәк.

Кыскасы, йомырка порошогы – сәламәтлеккә янамый торган, чын мәгънәсендә табигый продукт. Теге яки бу ризык рецептында йомырка күздә тотылса, һич шикләнмичә, порошогын гына да (суда эретеп) кулланырга мөмкин, дигән сүз.

Белеп тор!

Телеңне йотарлык

✓ Бәрәңге боламыгына пешкән йомырка сарысы, сыр (угыч аша уып) яки яшел тәмләткеч (петрушка, укроп, суган кыягы – ваклап турап) салып болгатыгыз. Телеңне йотарлык боламык килеп чыгачак!

✓ Майонез яки аш серкәсе һәм үсемлек мае белән ясалган башка соуска горчица өстәгән очракта, ризык аеруча тәмле булачак.

✓ Йомыркага бераз гына чүпрә өстәгәндә, йомырка тәбәсе кабарып һәм аеруча тәмле булып пешәчәк.

Кирәге чыгар

Эмале купмый

Яңа кәстрүлнең эмале озакка чыдасын өчен, болай эшләгез. Салкын су тутырып, кайнатып чыгарыгыз. Шуннан, газ утын сүндереп, кәстрүлдәге суны суынганчы тотыгыз. Болай эшләгәндә, эмале бик озакка чыдаячак.

БЕЛЕМЛЕ КУРЫКМАС

Курку – адәм баласын гомер буе озата барган хисләрнең берсе. Соңгы арада тормышыбызда аеруча ныклап тамыр җәя ул. Кеше дигәнең шатлык-куаныч белән генә түгел, курку белән дә сынала. Куркуга бирелүнең чиге бармы? Бу хистән ничек арынырга?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Адәм баласы беренче чиратта нәрсәләрдән куркырга тиеш?

– Кеше бу дөньяда, иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булудан куркырга тиеш. Бер хәдистә: «Кешенең йөрәгендә ике курку берләшмәс», – диелә. Әгәр кеше бу дөньяда Аллаһы Тәгаләдән, гөнаһлардан куркусыз хәлдә яшәсә, Кыямәт көнендә аның йөрәгендә җәһәннәмнән һәм Аллаһы Тәгаләдән курку булачак. Ул бу дөньяда, киресенчә, гөнаһлардан сакланыйм, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булмыйм, дип яшәсә, кыямәт көнендә йөрәгендә курку хисе булмаячак. Аннары кеше бу дөньяда әти-әнисенең ачуына, ләгънәтенә ирешүдән дә куркырга тиеш. Мондый хата ясаган очракта, алардан гафу үтенеп, бәхиллеген алырга кирәк. Адәм баласы кешене кимсетүдән дә куркырга тиеш. Аннан да гафу үтенү шарт.

:: Коронавирус, сугыш, яман шештән, хәерчелектән куркып, хәвефләнеп яшәүчеләр күп. Бу – гөнаһмы? Болардан курку тормышыбызга шушы ук хәлләрне тартып китерә аламы?

– Бу уңайдан Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Бу дөньяда мин сезне бернигадәр курку, ачлык, ялангачлык, сугыш һәм балаларыгызны югалту, корылык белән сынап карармын», – ди. Чир булсынмы, сугыш булсынмы, алар – бар сынау. Бу авырлыклар килгәч, түземлелек күрсәткән кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең әҗер-савабы булачак. Шушы вакытта, ягъни курыккан чакта кеше үзенең кешелеклелеген яки кешелексезлеген күрсәтә. Әгәр без алда алган күренешләрдән курыкып, файдага ирешсәк, ул очракта курку урынлы әле. Әйтик, сугыштан курыкканга күрә, дәүләтебезне корал ягыннан куәтлибез, саклыйбыз, төрле чаралар күрәбез, ди. Чирдән курку аркасында, сәламәтлегебезне кайгыртсак та урынлы булачак. Әгәр кеше бу дөньяда сәламәтлегенә, балаларының, дәүләтнең тынычлыгына битараф булса, сугышы да, чире дә киләчәк.

:: Куркуга ничек бирелмәскә?

– Әгәр кешедә чиста дөньяви һәм дини белем булса, анда курку хисе бик аз булачак. Андый кеше дөньяның тәртипләрен белә. Нәтиҗәдә анда курку урынына саклану хисе пәйда була. Белемле кеше үзен сихер-зәхмәтләрдән, җеннәрдән, шайтаннардан саклый. Сәламәтлек ягыннан да куәтле булырга тырыша. Фәкыйрь буласы килмәгәч, мөмкин кадәр күбрәк белем туплый, эшли, тырыша. Кыямәт көнендә ләгънәткә һәм җәһәннәмгә ирешәсе килмәгәч, бу дөньяда изгелекләр кылырга тырыша. Курку хисеннән әнә шул рәвешле арынырга мөмкин. Кеше аңа каршы берничек көрәшә алмаган, зәхмәт белән бәйле курку хисләре була. Бу – шайтан вәсвәсәсе. Андый чакта кеше үз-үзен өшкерергә тиеш. Моны дини кешегә барып та эшләргә мөмкин.

:: Курку хисеннән куркулык койдырып арынырга мөмкин, диләр. Кургаш ярдәмендә куркулык койдыручылар бар. Динебез моңа нинди мөнәсәбәттә?

– Коръән укып, догалар кылып эшләгән очракта ул өшкерүнең бер төре санала. Әгәр дә аны икенче бер сүзләр әйтеп башкарсалар, ул очракта куркулык койдыру тыела. Шуңа күрә куркулык койдыру өчен фәкать дини белеме булган, мәчеттә эшләгән кешегә генә барырга кирәк. Имам, остаз булмаган, Коръәнгә таянып эш итмәгән кешеләрдән сакланырга кирәк. Алар үзләре үк кешеләр арасында зәхмәт, курку тарата.

:: Укучыбыздан шундый хат килеп иреште: «Якын дустым фаҗигале төстә вафат булды. Фаҗига урынында аның мәетен күргәч, куркып калдым. Шуннан бирле күңел тынычлыгымны югалттым. Бөтен җирдә шул күз алдыма килә, караңгыда ялгыз калырга курка башладым. Психологларга баруның да файдасы булмады. Миңа ни эшләргә икән? Бу куркудан ничек котылырга?» Укучыбызга нинди киңәш бирер идегез?

– Артык сөенгән, курыккан, борчылган, артык хәлсезләнгән вакытта шайтан зәхмәт салырга мөмкин. Ул үзен курку хисе буларак сиздерә. Кешенең күзенә күренә, ул өйдә үзе генә калырга, караңгылыктан курка башлый. Шайтан аның шул рәвешле фикеренә үтеп керә алган. Бу очракта нәрсә эшләргә кирәк? Иң беренче чиратта, өйдә ешрак Коръән тыңларга кирәк. Моны бүген телефон аша да, телевизор аша да эшләргә мөмкин. Икенчедән, йортыбызда сурәтләр булырга тиеш түгел. Мондый куркудан котылу өчен, өшкерүче хәзрәткә дә мөрәҗәгать итәргә була. Иң мөһиме – үзебезгә дә, шушы куркудан арындыруын сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялварып, дога кылырга кирәк.

Йәгез, бер дога!

КУРЫККАНДА УКЫЛА

«Әллааһүммә әсләмтү вәҗһии иләйкә вә фәввадтү әмрии иләйкә вә әлҗәәтү заһрии иләйкә раһбәтән вә рагбәтән иләйкә ләә мәлжә-ә вә ләә мәнжәә минкә илләә иләйкә әәмәнтү би китәәбикәлләзии әнзәлтә вә би нәбиййикәлләзии әрсәлтә».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Үземне Сиңа тапшырдым, эшемне Сиңа калдырдым, аркамны Сиңа сөядем. Сиңа таяндым. Синнән өмет итеп һәм Синнән куркып, тагын Сиңа килдем, Аллаһым! Синнән башка сыеначак башка урын юктыр. Аллаһым! Иңдергән китабыңа, күндергән пәйгамбәреңә инандым».

ИМТИХАНГА КЕРГӘНДӘ УКЫЛА

«Әгүүзү-билләәһи-минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмил-ләәһир-рахмаанир-рахиим. Аллааһу ләә иләәһә илләәһүү әлхәййүл кайюм, ләә та-хузухүү синәтүү-үә ләә нәүүүм, ләһүү мәә фиссәмәәүәәти үә мәә фил-әрд, мәң зәл-ләзии йәшфәгу гиңдәһүү илләә би изниһ, йәгләмү мәә бәйнә әйдииһим үә мәә хальфәһүм үә ләә йүхиитуунә би шәйим-мин гильмиһии илләә би мәә шәә‘а, үәсига күрсиййюһу ссәмәәвати үәль-әрд, үә ләә яудуху хифзухума үә һүвәль-галиййюль-газыыыйм».

Мәгънәсе: «Һәрбер күркәм сыйфатны җыйган Зат, гыйбадәт кылына торган һичбер хаклы

зат юк, мәгәр һәрбер күркәм сыйфатны җыйган Аллаһы Тәгалә генә. Ул Аллаһ терек, һаман халык белән идарә итеп торучы. Ул Аллаһы Тәгаләне ару һәм йокы тотмас, ягъни Аллаһы Тәгаләдә йоклау һәм ару сыйфатлары юк. Күкләрдә һәм җирдә булган нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнеке. Аллаһы Тәгалә каршында шәфәгать кылучы кем бар, ягъни һичкем шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән генә шәфәгать кылыр. Аллаһы Тәгалә кешеләрнең алларында һәм артларында булган нәрсәләрне белер. Бәндәләр Аллаһы Тәгалә белгән нәрсәдән һичнәрсәне камил белмәсләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә белдерергә теләгән нәрсәне генә белерләр. Аллаһы Тәгаләнең көрсие күкләрне һәм җирне сыйдырды. Дәхи Аллаһы Тәгаләгә күкләрне саклау авыр булмас. Аллаһы Тәгалә шәрикләрдән (иптәш) пакь булучы». («Һәфтияк Шәриф» китабыннан алынды).

Нәсыйхәт

Бирәү дә күрмәгән

– Арча урманчылыгында эшлим. Колга башына менә башлавыма – 29 ел. Быел да Сабан туйларда ярышырга җыенам. Әмма яшь барган саен, барысына да йөреп булмый шул. Элек район, шәһәр, хәтта Мәскәүнекендә дә катнашканым бар. Кызым Әмирәгә – 6, улым Альмирга – 13 яшь. Алар да колгага менә хәзер.

Кечкенә чакта агач, койма башыннан төшмәгәнмен. Шомарымның хикмәте шундадыр. Элегрәк аякны кока-кола белән юешләп җибәрә идем. Сагыз сылаган бар, тик файдасы юк. Кузгалып киткәндә генә булыша. Аяк ышкылып авыртмый үзе. Колгага менү өчен үзенә күрә бер сәләт кирәк дип уйлыйм. Күнегүләр ясамыйм. Гәүдәм җиңел.

Алган әтәчләремне санап бетерерлек түгел. Көнгә 5–6 колгага менә идем бит. Күбесе чыгып качты, суеп та ашадык. Иң зур бүләгем – телевизор.

9 июньдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Мирасны ничек бүләргә?

Ирем үлгәнгә 6 ай булды. Бергә яшәгәндә йорт төзеп чыккан идек. Ул аның исемендә иде. Хәзер минә туганнары иремнең өлешен сорый. Уйлап утырам әле: 32 ел бергә яшәп, бергә йорт салып, урамда калмаммы? Мирас ничек бүленә?

Кәнифә ЛАТЫЙПОВА. Лаеш районы

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:
– Мирас алу өчен, нотариуска мөрәҗәгать итәргә кирәк. Нотариус мирас эшен ача. Гомуми кагыйдә буенча мирас алу вакыты – 6 ай. Әгәр васыять төзелмәгән булса, мирас алу чират буенча закон нигезендә бара. Закон буенча, беренче чираттагы варисы булып, балалар, тормыш иптәше һәм әти-әнисе тора. Йорт уртак милек булып саналса, димәк, аның 1/2 өлеше – хатыныныкы. Шулай итеп, үлгән кешенең йортның калган 1/2 өлеше генә мирас итеп алынырга тиеш. Бу өлеш беренче чираттагы варислар арасында тигез итеп бүленәчәк. Мәсәлән, ике бала булса, һәр бала 1/6 өлеш алачак. Нәтиҗәдә хатынның өлеше – 2/3, балаларның өлеше 1/6 булачак.

Түләп укыганга акча кайтамы?

Кызым икенче елын түләүле бүлектә укый. Уку өчен салымны кире кайтарып була, дип ишеткән идем. Түләп укыткан очракта, моны ничек эшләргә?

РОЗАЛИЯ. Яшел Үзән

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:
– Баланың укуы өчен түләгән чакта, ата-аналар чынлыкта тоткан чыгымнары күләмендә (әмма елына 50 мең сумыннан гына) салым «вычет»ы кайтара ала. Шулай итеп, һәр бала өчен 6500 сумга кадәр НДФЛ кайтарырга мөмкин.

Россиядә эшләп, 13 процентлы ставка буенча салым түләгән ата-аналар салым чигерүен ала. Әгәр укыган өчен акча түләгән елда ата-аналарның салым салына торган кереме булмаса, «вычет» кайтару мөмкин түгел. «Вычет» 24 яшькә кадәрге балаларны көндезге уку формасында укыткан очракта гына бирелә.

Салым чигерүен ике ысулның берсе белән алырга мөмкин:

• агымдагы елда – эш бирүчедән. Моның өчен Салым федераль хезмәте сайтындагы шәхси кабинет аша ташламага хокук турында хәбәрнамә алырга һәм аны эш бирүчегә тапшырырга кирәк;

• ел тәмамлангач, салым органына декларация тапшырып. Декларацияне уку өчен түләнгән елдан соң өч ел эчендә бирергә мөмкин.

Нинди документлар кирәк булачак? Уку килешүенең күчермәсе, мәгариф оешмасының лицензиясе күчермәсе (әгәр дә аның реквизитлары килешүдә булмаса), түләү документларының күчермәләре, көндезге уку формасы турында белешмә (әгәр килешүдә күрсәтелмәсә), бала белән туганлык турындагы документның күчермәсе, 2-НДФЛ формасы буенча керемнәр турында белешмә, никах таныклыгы (әгәр түләү документлары икенче ата-анага рәсмиләштерелгән булса).

«Татар-информ»

Өстәмә каралганмы?

Әниемә күптән түгел 80 яшь тулды. Быелдан шушы яшькә җитүчеләрнең пенсиясенә өстәмә акча каралган, дип ишеткән идем. Пенсиясе 7 мең сумга арта икән, диләр. Бу – дөрес хәбәрме?

Алия САФИНА. Казан

Альбина НИКАНДРОВА, Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте җитәкчесе:
– 80 яше тулган пенсионерлар картлык буенча иминият пенсиясенә фиксацияләнгән түләүне арттырырга хокуклы. Пенсионерга беркая барырга да, бернинди гариза бирергә дә кирәкми. 80 яшь тулган айга өстәмә үзеннәнүзе күчәчәк, туган көннән соң киләсе айдан түләнәчәк. 2023 елда пенсиягә өстәмә 7567,34 сумны тәшкил итә.

Халык кәефе

Илсаф ТИМЕРБАЙЕВ, клуб мөдире (Теләче районының Баландыш авылы):
– Авыл халкы өчен җәй – «кызу» чор. Авыл кешесенең эше бетми. Иртәдән алып кичкә кадәр урамда без хәзер. Сөтү, төзү эшләре гөрләп тора, авыл кайный, һәр җирдә хәрәкәт, эш! Һава торышы да сөендереп тора, шуңа барысына да өлгерергә тырышабыз. Кыскасы, тәүлегенә 24 сәгать кенә җитми! Тиздән милли бәйрәмебез җитә. Бу көннәрдә Сабан туена бирнә җыярга чыгабыз. Бу җәйдә авылда кызыклы чаралар оештырып калырга телим. Яшьләр өчен яңалык кертәсе килә. Җәйне хәвеф-хәтәрләрсез үткәрсәк иде. Матур көннәрнең кадерен белергә кирәк.

Зөлфия БАТЫРШИНА, 75 яшь (Константиновка бистәсе):
– Киленем өченче баласын көтә. Иң зур сөенечем шул. Монысы ир малай булыр, дибез инде. Моңа кадәр чибәр кызлар белән куандырды. 4 яшьлек олы оныгым кул арасына керә башлады инде. Үз йортыбыз булгач, бакча эше дә бар бит. Аның белән мәш киләбез шунда. Булышам, ди, чүп тә уташтан итә, орлыклар да чәчә. Телефонны бик бирмибез. Баланы боза ул. Иң яхшысы – безнең янда йөрсен, эш эшләмәсә дә, эшләгән булып кылансын. Без хәзер оныклар дип яшибез инде.

Луиза СӨНГАТУЛЛИНА, «Кайбыч таңнары» газетасы баш мөхәррире:
– Хәзер газетага язылуның иң кызган чоры бара. Газета мөхәррире булырак, тиражны киметәсе килми бит. Бөтен коллектив шул эш белән шөгыльләнә. Халыкка газетаны мөмкин кадәр күбрәк таратасы килә.

Авылларга чыгып йөрибез. Авыл халкы зарланмый инде ул. Булганына шөкер дип торалар. Кайбычлылар бигрәк тә. Кешеләр белән сөйләшәбез, фикерләшәбез. Безнең район – күпмилләтле җирлек. Хәзер бар кеше бакчада казына, яшелчәсен, бәрәңгесен үстерә, чүбен утый. Яңгыр булмавы көендерә инде. Үзем – Актаныш кызы, үземнекеләр белән элемтәдә торам. Аларда яңгыр бөтенләй юк. Шуңа безгә әле булган яңгырга да шөкер итеп торасыдыр. Күңел Сабан туен көтә. Өйдән-өйгә кереп, борынгы йолаларны үтәп, сөлге, яулык җыюлар гөрли.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Рәхмәт сүзе

Ике балабызның бу дөньядан китүләренә менә инде бер ел ярым вакыт үтеп бара. Улыбыз Илнур, киленебез Ләйсәнне искә алмаган минутыбыз юк, йөрәктән әкрен генә сыкрап кан тама. Бу яра – безнең гомер азагына җитәрлек яра инде. Шулай да тормыш дәвам итә, яшәргә кирәк, кызларыбызны аякка бастырасы бар. Әдилә дә, Ясминә дә бик сабыр бала булдылар. Бәгырькәйләребез, без еламасын дип, күзгә генә карап торалар. Бик авыр хәлләр төште башыбызга, Ходай бирәүгә дә бала хәсрәтләре язмаса иде!

Шушы вакыйгалардан соң без Әсхәтем белән әле яңа гына аңыбызга киләбез кебек, рәхмәтебезне җиткерер вакыт та җитте. Без балаларны озаткыннан бирле ишегебез ябылып тормады, авыр вакытта мәрхәмәтле кешеләр терәк булды.

Бик зур рәхмәтебез – ДРКБ, РКБ хастаханәләренә, барлык табибларга, бүлекләрдә эшләүче медицина хезмәткәрләренә, шәфкать туташларына, бөтен коллективка. Саусәламәт булсыннар!

52 нче гимназиянең ярдәме иксез-чиксез булды. Директорыбызга, сыйныф җитәкчесе, барлык укытучыларга һәм әти-әниләргә, Ясминәнең сабакташларына саулык-сәламәтлек телибез. Изге теләкләребез аларга да меңе белән иреушен!

КАИ көллияте җитәкчеләре, укытучылары, әти-әниләре, группадаш иптәшләре, дус кызлары Әдиләгә кызыбызга бик нык ярдәм кулы суздылар, аларга рәхмәт яусын.

Кадерле әтиебезгә зур рәхмәт. Сабыр булдылар, әниебез белән гел ярдәм итеп тордылар. Әсхәтемнең бертуганнары, үземнең туганнарым хәл белешеп торды, хастаханә юлыннан кайтып кермәде, кызларыбыз янында булды. Моңа өстәп, авылдашларыбызга да зур рәхмәт! Ике буын туганнар, кода-кодагыйлар, хезмәттәшләргә дә рәхмәт ирешсен! Авылдашларга, күршеләргә, Ләйсәнебезнең дусларына, соңгы вакытта бергә эшләгән кызларына, мәчеттәге хәзрәтләргә дә, танышларга да рәхмәт сүзләре җиткерәм.

Минем бу рәхмәт хатымда ярдәм кулы сузганнарның барысын да санап бетерерлек түгел. Аллаһы Тәгалә рәхмәтне кабул итсен, теләгән теләкләрем, укыган догаларым кабул булсын.

Диләрә ГЫЙЛЕМХАНОВА

P.S. Әлеге ханымның язмышы газета һәм сайт битләрендә басылган иде.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ҮЗ ӨЕМДӘ – ҮЗ КИЕМЕМ

Кыенлыклар чыныктырды гына! Татарстанның җиңел сәнәгать тармагы вәкилләре, ягъни безгә кием тегүчеләр әнә шулай ди. Чит ил брендлары илдән бер-бер артлы чыгып киткәннән соң, кияргә рәтле күлмәк-чалбар да юк, дип хафага төшкән чаклар, мәзәк кенә булып, артта калмагае. Бушаган киштәләрне үзебезнең җитештерүчеләр тутырырга әзер. Ничек кенә әле! Ел азагына кадәр илдә үзебезнең брендлардан торган 400гә якын яңа кибет ачылыр дип фаразлана.

«Зара»ның эзе дә юк!

Кибеттән киенергә яратучылар узган ел илдән киткән чит ил брендлары арасыннан күбрәк «Зара»ның ябылуын авыр кичерде бугай. Шуңа күрә аның икенче исем астында Россиягә яңадан әйләнеп кайтуы турында хәбәрне бик сөенеп кабул иттеләр. Казанда «Зара»дан «Мааг»ка әйләнгән кибет апрель азагында ачылды. Кием-салымның сыйфаты шул ук микән дип, сәүдә үзәкләренең берсендәге кибеткә «ВТ» хәбәрчесе дә барып кайтты.

Башка кибетләр белән чагыштырганда, биредә халык күбрәк, хатын-кызлар киемнәре рәтләре арасында да, балалар киемнәре бүлегендә дә шактый кеше йөри.

– Сыйфаты элеккечәме? – дип сорыйм сатучыдан.

– Безне «Зара» белән бутамагыз, бу – бөтенләй яңа бренд. Кием-салымнар да аерыла. Без «Зара» кибетләре урынына ачылдык, шул гына. Ә менә товарларның сыйфаты аларныкыннан ким түгел. «Мааг» – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре бренды. Хатын-кызлар киемнәрендә бераз синтетика бар, ә менә ирләр һәм балалар өчен күлмәк-чалбарлар яхшы киҗе-мамык тукымадан эшләнгән, – диде ул.

2 миллиард евро

Рәсми мәгълүматларга караганда, Россия базарыннан киткәннән соң, «Inditex» шуның кадәр акчасын югалткан.

Билгеле булганча, «Зара», «Бершка», «Страдивариус» кебек брендлар иясе булган «Inditex» Испания компаниясе узган елның язында Россиядә үз бизнесын туктатты.

Соңрак бизнесын Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең «Daher» төркеменә сатуы да билгеле булды. Шул рәвешле, «Зара» – «Мааг»ка, «Бершка» – «Экру», ә «Страдивариус» – «Вилет»ка әйләнде. Хәер, чит ил кибетләренең исемнәре үзгәрүгә ияләштек инде. Кайбер брендлар, четерекле хәлдән чыгу өчен, ел башында ук исемнәрен кыскартып, яңадан ачыла башлады. Тик бу юлы яңа кибетләрнең моңарчы гамәлдә булганнарына бернинди дә катнашы юк икән. Моны сатып алучылар да сизгән.

– Монда «Зара»ның эзе дә юк. Иске коллекцияләрне булса да сатарлар дип өметләнгән идем. Мондагы күлмәк-чалбарлар исә без моннан дистә еллар элек кигәнне хәтерләтә, – ди Казанда яшәүче Альбина Хаҗиева.

Бәяләргә килгәндә, хатын-кызлар чалбары – 4000 сум, ир-ат футболкасы – 1600 сум, малайлар ыштаны 1200 сум тора. Биркаларыннан күренгәнчә, кием-салымны Бангладеш, Пакъстан, Кытай кебек илләрдә тегәләр. Чит ил брендларына ышаныч юк, дигән уй белән кибеттән чыгып киттем.

Базарның яме качкан

Хәзер кием-салым бәясе базарда да арзан түгел. Сатучылар моны башкалар кебек үк дөньядагы вазгыять аркасында доллар кыйммәтләнү, логистика үзгәрүгә бәйләп аңлата. Башкаланың Вьетнам базарында хатын-кызларга җәйге чалбар да, ирләр футболкасы да, балалар күлмәге дә уртача 1500 сумнан башлана. Кайбер сатучылар, «синең өчен генә» дип, өйгә кайтырга автобус билетына 50 сум ташлама ясый.

Белгеч сүзе

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:
– Чит ил брендларының чыгып китүе безгә нинди зыян китерәчәк? Бернинди дә. Минемчә, бу күбрәк халыкны котырту өчен эшләнде. Тик телләгәннәренә ирешә алмадылар. Китсеннәр! Безнең үзебезнең җитештерүчеләр дә җитәрлек. Аларга чынбарлыкка яраклашу өчен вакыт кына кирәк. Кичә илдән чыгып киткән кибетләрнең иртәгә, кире кайтырга сорап, ишек шакулары да бар. Чөнки бизнесны алып бару өчен даими акча әйләнеше кирәк. Тик аларның безгә кирәге калырмы, монысы инде – икенче мәсьәлә.

Таңсылу Галимова

– Егерме ел базарда сату иткәннән соң, узган елның җәендә заводка эшкә кердем, – ди Нәҗия Газизова. – Вьетнам базарына кадәр Колхоз базарында эшләдем. Балалар өчен киемнәр, шул исәптән чит илнекеләрне дә сата идем. Билгеле хәлләр барыннан да бигрәк безнең кебек алыпсатарлар кесәсенә сукты. Товар алып кайту кыенлашты, бәяләр күтәрелде. Тик мин дә үземә зыянга эшли алмыйм бит. Озак уйлаганнан соң, былтыр сәүдәне туктатып, заводка эшкә кердем. Миңа кадәр дә, миннән соң да базардан китүчеләр булды. Беребез дә үкенмибез. Төш вакытында рәхәтләнеп бер сәгать буе иркенләп ашап-эчеп була икәнен заводка эшкә кергәч кенә белдем. Хәзер елларда базарга килеп, калган товарларны сатып бетерәм. Әйберләрне үз бәясеннән бирәм. Мәсәлән, малайлар өчен Төркиядән кайткан спорт костюмы – 1400 сум, кызларга Кыргызстанда тегелгән күлмәк 200 сум тора.

Безнекеләр – Нью-Йоркта

Изге урын буш тормас, диләр бит. Әйткәнемчә, бушаган киштәләрне үзебезнең җитештерүчеләр тутырырга әзер. Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, былтыр республикада 400гә якын җиңел сәнәгать предприятиесе теркәлгән. Ел дәвамында алар 8 миллиард сумлык продукция җитештергән. Шул исәптән 4 миллиард сумлык кием-салым, 1 миллиард сумлык күн һәм күннән әйберләр эшләп чыгарганнар. Узган ел нәтиҗәләренә караганда, Татарстанның җиңел сәнәгать тармагы 5 процентка үскән. Бездә өлкәннәр һәм балалар киемнәре, махсус кием, мәктәп формасы, бер тапкыр кия торган медицина киемнәре, оек-оекбаш җитештерелә. Кыскасы, саннар кечкенә түгел.

– Кыенлыклар чыныктырды гына, – ди «ENNSTORE» кием бренды хуҗасы Светлана Зәйнетдинова. – 2018 елда эшне нәни кызчыклар өчен күлмәкләр тегүдән башлаган идек. Акрынлап малайлар өчен дә киемнәр җитештерә башладык. 2020 елгы пандемия чорында өлкәннәр коллекциясен чыгардык. Аңа шул дәрәҗәдә сорау зур булыр дип күз алдына да китермәгән идек. 2021 елда безгә Нью-Йоркта мода атналыгында катнашу бәхете тәтеде хәтта. 2022 ел да бик катлаулы булды. Пандемиядән соң җиңел сулап куярга да өлгермәдек, яңа сынау: сату ике мәртәбә диярлек кимеде. Ваклап сатуны арттырдык. Казаннан тыш, Мәскәү, Екатеринбург, Нью-Йоркта үз кибетләребез бар. Былтыр онлайн кибетләребез дә эшли башлады.

Ничек кенә булмасын, ертык киемнән йөрмәячәкбез, дип ышандыра белгечләр. Ел азагына кадәр үк илдә үзебезнең брендлардан торган 400гә якын яңа кибет ачылыр дип көтелә. Сүз, беренче чиратта, сәүдә үзәкләре турында барачак, ди. Бу җәһәттән әле шушы арада гына Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында узган чараларның берсендә республика эшмәкәрләре зур кибетләрдә үзебезнең җитештерүчеләр өчен кеше күбрәк йөри торган сәүдә урыннарын саклап тоту үтенече белән чыкты. Рәис ярдәм итәргә сүз бирде. Хәер, җиңел сәнәгать тармагы предприятиеләре белән ел дәвамында элемтәдә торалар. «Аларга импортны алмаштыру, чимал кайтару юлларын җайга салу кебек мәсьәләләрдә ярдәм күрсәтелә. Мәсәлән, узган ел республиканың әйдәп баручы җиңел сәнәгать предприятиеләре вәкилләре Үзбәкстанга барды. Нәтиҗәдә ике арада трикотаж тукыма, мамык җеп кайтаруга бәйле килешүләр төзелде», – диделәр Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының матбугат хезмәтендә.

Фикер

Сәфинә СӨЛӘЙМАНОВА,
«IDA PROSPORT» компаниясен оештыручы:
– Чит ил компанияләренең китүе безгә уңай тәэсир итте, чөнки ихтыяҗ артты. Икенче яктан, таләпләр дә зуррак. Без хәзер чит илдәге көндәшләребезгә тиң булырлык кием-салым җитештерергә тырышабыз. Чит ил брендларының китүе безнең өчен үсеш ноктасына әверелде. Дөрес, чимал сатып алуга бәйле кайбер кыенлыклар туды. Мәсәлән, спорт курткалары өчен тукыманы Италия һәм Испаниядән сатып ала идек. Ахыр чиктә аларны Төркия һәм Кытай фабрикаларында җитештерелгәннәренә алмаштырдык. Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы ярдәме белән Үзбәкстанга барып кайттык. Шуны әйтәсем килә: Үзбәкстанда да сыйфатлы чимал җитештерергә өйрәнгәннәр. Аннан лайкра кушылган мамык тукыма сатып алабыз. Баштарак спорт һәм өс киемнәре тегүчеләр буларак танылсак (мәсәлән, «Ак барс» хоккей командасы өчен киемнәр тегәбез), хәзер кием-салымга ихтыяҗ зур булуын күреп, товар төрләрен арттырдык. Яшьләр таләпләренә туры китереп, спорт костюмнары, озын футболка, кепкалар тегәбез. Быел Казанда үзебезнең фирма кибетен дә ачарга җыенабыз.

Айгөл КАМИЛОВА,
«SULTAN» бренды хуҗасы:
– Ун елга якын авторлык эшләнмәләре белән сату итәбез. Милли бизәкләргә зур урын бирелә. Бу – бик күп вакыт таләп итә торган хезмәт. Бизәкне уйлап тапканчы, аны тукымага төшергәнче шактый вакыт уза. Орнаментларны үзебез уйлап табабыз. Бу эштә каенанам ярдәм итә, ул – дизайнер. Хатын-кызлар өчен милли бизәкле сумкалар, аяк киемнәре, билбауларга сорау зур. Тик сатып алучыларыбыз – күбрәк илнең башка төбәкләрендә яшәүчеләр һәм чит ил халкы. Минем уйлавымча, бездә яшьләр күбрәк Көнбатыш модасы белән кызыксына. Алар һаман да шул «Зара»ларга тартыла. Ә үзебезнең брендларга, бигрәк тә, милли киемнәргә өстенлек бирергә ашыкмыйлар. Бәяләргә килгәндә, миллилек кыйммәт тормый дип саныйм. Мәсәлән, безнең бизәкле билбау 4000 сум тора. Бу – тиңе булмаган, кабатланмас эшләнмә. Иртәме-соңмы миллилек тә модага керәчәк дип өметләнәбез.

Үҗәт Айрат

Теләче егете Айрат Якупов бик күп бәйгеләрдә җиңү яулаган. Матур итеп шигырьләр сөйләве, моңлы җырлавы белән сокландыра ул. Әмма тамашачыны гаҗәпләндерер өчен бик күп сынаулар аша узарга туры килә аңа. ДЦПлы егет үзенең тырышлыгы белән башкаларга үрнәк күрсәтә.

Айрат Кәрим Тинчурин театры каршында эшләп килүче «Могҗиза» студиясенә дә йөри. Киләчәктә артист булырга, матур гаилә корырга, балалар үстерергә хыяллана. Әнисе дә улының уңышларга ирешәсенә ышана.

– Саба районының Иләбәр авылы кызы мин. Булачак ирем белән бер җәйге кичтә таныштык. Ул безнең авылга кунакка килгән иде. Клубтан озата кайтты, – ди Люзия. – Айдар эшне тиз тотты. Арча районының бер авылына бәрәңге алырга кайтканымны белеп алды да шуннан мине урлап алып кайтты. Шөкер, шул көннән бирле бик матур гомер итәбез.

Язмыш аларны төрлечә сынап карый. Әмма бирешми Якуповлар. Башта бәбиләре булмыйча тора, аннан инде кулларына алып сөясе кызлары вафат була. Бик аз гына яшәп кала сабый. Авыр чакларында ире терәк була. Люзия тагын авырга уза. Табиблар баланың төшүе бар, дип кисәтә, сакланырга кушалар.

– Айратыбыз 2003 елның апрелендә җитлекмичә туды. Яшьтәшләреннән калышуын да шуннан күрдек. Әмма сынауның зуры алда булган икән әле. Вакытында утырмагач, гәүдәсен тотмагач, борчыла башладым. Күңел сизенгән: 1 яшь тулып киткәч, улыбызга ДЦП диагнозы куйдылар, – дип сөйли Люзия. – Баштарак бик кайгырдым. Ничекләр үстербез, дигән идем. Әмма улым безгә яшәр көчне үзе бирде. Аның акылына зыян килмәгән, шигырьләр ятлый башлады. Айратның яшәргә тырышуын күреп сокландым. Ул тормышның якасына ябышкан иде. Менә шунда мин үз-үземне кулга алдым. Баламны ничек бар шулай кабул итеп яшәргә өйрәндем. Балалар бакчасына да бергә йөрдек. Мин янәшәсендә көтеп утыра идем. Андагы сабыйлар шулкадәр үз итте Айратны. Ул үрмәләп китеп баргач, калган балалар артыннан иярә. Зуррак гәүдәлеләре аны аркаларына да утыртып йөри иде. Мәктәптә дә якын иттеләр аны. Берәү дә начар сүз әйтмәде. Кайбер чакта дорфарак эндәшеп куючы табыла инде ул. Әмма без моңа игътибар итмәскә өйрәндек.

Люзия улын бер минутка да калдырып китә алмый. Гел янәшәсендә була. Дөрес, авыр чакларда ире булышса, туганнары ярдәм кулы суза. Бар булган акчаларын Айратны дәвалауга тоталар. Максатлары – ничек тә улларына ярдәм итү. Люзия Айратны тормыш итәргә өйрәтеп калдырырга тели.

– Гел без янәшәсендә дә булмабыз. Өй эчендә тотынып йөри ала ул. Киләчәктә аякларына басып, үз-үзен йөртә алса иде. Тернәкләндерү курсларына да йөреп торабыз. Улым үзе дә күнегүләрне калдырмаска тырыша, – ди әнисе.

Айдар белән Люзия Айратка иптәшкә тагын бала алып кайтырга телиләр. Тик насыйп булмый. Ә Айратка сеңелкәш кирәк! Уйлашалар да приюттан бик матур кызчык алып кайталар. Моннан биш ел элек була ул хәл. Люзия Диләрәне бер күрүдә ярата. Кызчык та кунакка дип кайткан җиреннән башка китәргә теләми.

– Кәгазьдә генә тәрбиягә алынган ул. Йөрәктә – үзебезнеке! Шулкадәр үз иттек. Диләрә «абыем» дип кенә тора, Айрат аңа сүз дә әйттерми. Алар арасындагы җылы хисләрне әйтеп бетереп булмый, – ди Люзия. – Улымның авыруын Аллаһы Тәгаләдән бирелгән бер сынаудыр дип кабул иттек. Димәк, без аны үтәргә тиеш. «Әнием» дип өзелеп торучы балаларым бар. Алар өчен миннән дә кадерле, газиз кеше юк! Бәхетнең иң олысы инде бу!

СӘВИЯ МӨХӘММӘТҖАНОВА:

«УЛЫМНЫҢ ӘНИСЕН ТАБАСЫ ИДЕ»

Язылганга кире кайтып

2014 елның июлендә Кукмара районында булган фаҗигане күпләр хәтерлидер. Ядегәр авылында бер гаиләдән алты кешенең гомере янгында өзелде. Рөстәм Волков, аның хатыны Зөлфия, кызлары Рузилә, уллары Айрат һәм Айзат, кияүләре Искәндәр, Рузиләнең туарга өлгермәгән сабые да ут корбаны булды. Өч малай – Илфат, Илгиз, Илназ өйдә булмау сәбәпле, исән калалар.

Фаҗигадән соң «ВТ» журналисты баласын һәм оныкларын җирләгән Сәвия Мөхәммәтҗанованың хәлен белеште. Без кайтканда, мәрхүмнәрнең ашларын уздырып йөриләр иде. Андагы күз яшьләре, йорт тулы сагыш, хәсрәтле йөзләр әле дә күз алдында. Еллар узса да, бу гаилә белән элемтә югалмады. Сәвия апаның кызы Гөлияне социаль челтәрләрдә даими күзәтеп баргач, гаиләнең хәлләрен азмы-күпме белеп торабыз.

«9 минутка да онытмадым»

– Бу хәсрәт мине бик бетерде. Авыртмаган җирем юк. Җитмәсә, коронавирус та эләктереп, озак тилмердем. Кан басымым йә менеп китә, йә кинәт төшә. Әмма башка балаларым өчен дип тырмашып яшим, – ди Сәвия апа.

Бүгенгесе турында сөйләшкәндә, аның белән үткәннәргә кайтмый булдыра алмадык.

– Киленебез безгә дүрт бала – Рузилә, Илфат, Илгиз, Илназ белән килде. Җитмәсә, җиде яшькә олырак та иде әле. Бер-берләрен ошаткач, каршы килмәдек. Матур гына яши башладылар. Уртак балалары Айрат һәм Айзат туды. Искә алган саен елыйм, – дип күз яшьләрен сөртә ул.

Зөлфиянең өч улы хакында да сораштым. Олысы өйләнеп, матур итеп гаилә корып яши, ди. Ә менә Илгиз белән Илназның тормышлары кыек юлга кереп киткән. Илгиз, ирегеннән мәхрүм ителеп, тимер рәшәткә артында да утырып чыккан. Әлегә авылга кайтмаган. Сәвия апа кайдалыгын белми. Илназ исә психик авырулар хастаханәсенә эләккән. Кайчан кайтасын белмиләр.

– Нилләр генә күрмәдем инде мин, кызым. Кияүгә чыккач та, балабыз булмады. Ирем Мәгъфүргә суык тигән, балагыз булмый, диделәр. Ә гаиләне сакларга кирәк. Иремнең әти-әнисе дә безнең бергә булуыбызны теләде. Аерылыша күрмәгез, приюттан бала алыгыз, дип тордылар. Мин күргәннәрем турында «Азат хатын» журналына хат яздым. Бер айдан каян бала алып буласын әйтеп, җавап яздылар. Әни белән Казанга чыгып киттек. Бер бала тудыру йортында 10 көнлек малай бар, диделәр, – дип сөйли Сәвия апа. – 1981 ел иде бу. Гыйнвар ае. Минем исәп белән бала 18–19 гыйнварда туган булырга тиеш. Балага 10 көн тулгач, аны приютка күчерәселәр икән. Бу хакта белдем дә, табибка кереп, миңа бирегез бу сабыйны, дим. Ә ул, ике көн эчендә документлар җыеп алып килә алсаң, бирербез, дип чыгарды. Сабыйны барып күрәсе иттек. 1 кило да 800 граммлы малай. Йөрәк урыныннан кузгалды. Күрдем дә берәүгә дә бирәсем килми бит! Әнием исә, ала күрмә бу баланы, дип тора. Алам булгач алам дип, чуп-чуп итеп улымны үбәм. Ярамый, диләр. Мин аларны ишетмим дә...

Сәвия апа ничек итсә итә, табиблар белән уртак тел таба. Казаннан малайлы булып кайтып китә. Кызганыч, әнисенең кем икәнен әйтүче булмый, бары тик дәрәҗәле җирдә укучы студент кыз диләр. Сабыйга Рөстәм исеме кушып, үз фамилияләрен бирә алар. Кызганыч, парлы тормыш бары бер кыска булып чыга. 4 елдан ире Мәгъфүр абый вафат була.

– Мин улымны фермага ияртеп эшләп йөри башладым. Бик яраттым, үзең тапмыйча да, газиз була икән ул. Салам өсләрендә йоклап үсте балакаем. Шуннан соң мине бер иргә димләделәр. Яшәп киттек. Тагын ике улыбыз, бер кызыбыз туды. Рифат исемле улым сигез яшендә суга батып үлде. Аннан кабат ирсез калдым, – ди Сәвия апа. – Рөстәм улымның язмышын беләсез инде. Оныкларымны да бик сагынам. 9 ел вакыт узса да, алар минем күңелдән 9 минутка да китеп тормый. Айзатым белән бер елны туган балаларны күрәм дә, улыма да 14 тулыр иде, дим. Айратым да 16 яшен тутырып, мыеклар чыгар иде инде. Фаҗига буласы көнне оныкларым: «Әбием, иртәгә Кукмарага барабыз, мәктәп өчен киемнәр алабыз», – дигән иде. Насыйп кына булмады.

«Әнигә әйтегез, еламасын!»

Фаҗигадән соң Сәвия апаның улы Илшатның хатыны Ләлә төш күрә. Рөстәм кайткан икән. Сез үлдегез бит, дигәненә, юк, Ләлә, үлмәдек, дип җавап бирә. «Өй яна башлагач, өстебезгә япма төште дә безне саклап калды. Абзар артында йортыбыз бар бит. Әнигә әйт әле, еламасын!» – ди икән. Яңа йорт дип зиратны әйтүе булган, күрәсең. Сәвия апа хәзер бик еларга тырышмый. Үзен кулда тота. Әмма улымны сагынуга түзә алмыйм, ди. 10 көннән алып 33 яшенә кадәр үстергән баласы белән алар арасында аеруча көчле ярату була.

– Әниеңне эзлик, дигәнемә, син – минем әнием, дип җавап бирде. Улым бер дә тапкан әнисе турында сөйләгәнне яратмады. Минем ул кызга ачуым юк. Яшь чакта кем ялгышмый. Хаталангандыр. Укып та бетерәсе булганга, баласын ташлап калдыргандыр. Начар кеше түгелдер ул. Рөстәмем бит әнә нинди зур йөрәкле иде! Башлы иде дә әле ул. Әнисе укымышлы булгангадыр инде. Ул кыз укып чыгып, гаилә коргандыр. Бу баласы йөрәгендә булса да, ташлаган улым бар дип, берәүгә дә сиздермәгәндер, – ди Сәвия апа. – Үзем исән чагында Рөстәмне тудырган ханым белән очрашасым килә. Сабыен калдырып, мине бәхетле әни иткәне өчен рәхмәт әйтер идем. Улыбыз турында сөйләр идем. Кечкенә чактагы фотоларын күрсәтер идем. Сөйләр сүзләрем җитәрлек минем. Очрашсак иде. Шуңа күрә «Ватаным Татарстан» укучыларыннан да ярдәм сорыйм. Улымның әнисе үзен таныса, **89274385613** телефон номерына хәбәр бирсен иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РҮЗӘЛ МӨХӘММӘТШИН

КЫСКА ЮЛ

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 26 май санында

Бары – ап-ак очкыч эзләре...

Зәңгәр илаһилыкның җөennән сүтелгән урыннары гүя...

Йа Хода, ничек матур бу дөнья!

Йа Хода, ничек күңелле бу яшәү!

Сау кеше өчен бөтенләй рәхәткә тиенеп туймас көннәр якынлаша.

Нәкъ минем кебек, Шөн уртасында Рүзәл дә өнсез калган иде.

Тирә-юньне барлап алганнан соң ул күкрәк тутырып сулады да:

– Сыерчык бураны – кышның Ватерлоосы, – дип куйды.

Без авыл буйлап киттек. Каршыга сыңар кеше-кара да очрамады. Кайда бу халык? Якты көздә өйләрендә посып утыралар микәнни? Юлыбыз Толлы ягына каерылгач кына җил өтек-төтек авазлар китерде:

– Дәвәнәй!..

– Җаппашмайт!..

Икебез берьюлы тавыш килгән тарафка борылдык: безнең яшьләрдәге үсмер малай чаттагы йорт түбәсеннән кар төшерә; ә аста, койма читендә исә кечкенә карчык, йодрыкларын болгый-болгый, аңа нидер аңлатамы, аны нигәдер әрлиме иде...

Басу читендәге тиреслеккә җиткәч, юл бетте.

Каршыбызда тоташ аклык басып калды.

– Ой-йо, – дип маңгаена сукты Рүзәл. – Мин кыш турында бөтенләй онытканмын бит.

Хактан да, басу таптап кына җәй саен монда юл салына иде. Ни Казанга, ни Кировка аның, билгеле, кирәге юк. Межа бит. Ул безгә – ике авыл халкына гына кирәк. Анысы да, күренгәнчә, җәйдә генә. Ә хәзер – кыш. Дөресрәге, яз башы. Хәер, барыбер түгелмени? Кәҗә сукмагы да юк, ичмасам.

– Сәгать ничә? – дип сорадым мин.

– Өч, – диде юлдашым.

– Безнең автобус хәзер авыл башыннан әйләнеп, кире Нократ Аланына кузгалачак. Артка нашатырь сөрткәндәй йөгерсәк, өлгерәбез әле. Ул, дүрттән калмыйча, шәһәргә барып җитәчәк. Дүрттә исә Кукмарага автобус бар.

Рүзәл йөзен чытты:

– Син нәрсә? Тегендә – кырык, монда – кырык, уртада – ун... Туксан чакрым ураргамы?! – диде, тугыз бармагын тырпайтып. – Авылың кул сузымында була торып?..

– Яхшырак тәкъдимең бар әллә?

– Бар.

– Нинди?

– Әйдә, колбаса ашыйбыз.

Иң беренче эш итеп колбаса дугасын урталай сындырдык.

Аннары, авызга зур-зур кисәкләр тыга-тыга... аклыкка кереп киттек.

Без башта кызыл гаскәргә каршы психик атакага күтәрелгән Каппель корпусы кебек ныклы, ышанычлы адымнар белән төз-туры бардык.

Аннары кар билгә җитте. Җиңнәргә, чалбар балагына, оекка кереп тулды. Адымнар авырайды. Ботинканы әледән-әле нәрсәдер аска, тирәнгә суырып ала башлады. Аны зәмһәрир салкын эченнән актарып, табып, тартып чыгару мең газапка әверелде.

– Беләсеңме, моңарчы иң зур хыялым туйганчы колбаса ашау иде, – дип еш-еш сулады Рүзәл, кар ерuыннан бүленмичә. – Дүрт тапкыр каптым менә. Һәм гарык булдым. Калганын нишләтәсе?

Колбаса хәзер, чыннан да, артык йөк иде.

Җавап урынына үз өлешемне читкә томырдым.

– Ә мин ташчы булырга хыялланам, – дидем, нигәдер. – Яисә һич югы рәссам. Юк, ташчы, мөгаен. Тегесе бигрәк абстракт нәрсә...

Дустымнан:

– Хыялланырга кирәк, – дигән хуплау сүзе ишеттем. – Үзең күрәсең: хыяллар тормышка аша.

Шул мизгелдә колбасаның икенче өлеше дә җил уңаена очты.

Озакламый безне Чапаев дивизиясе кырып салды гүя. Бөтенләй аяктан яздык. Шуышып баруга күчтек. Башта беребез юл ярды. Аннары икенчебез. Хәлдән тайган саен урыныбызны алыштык.

Бер калышкан чагымда мин Рүзәлгә күтәрелеп карадым. Ул иң элек телефон аппаратын метр ярым алга тотып ата, аның артыннан берешәрләп ботинкасын ташлый, шуннан соң гына үрмәли-үрмәли үзе аларны куып җитә дә, ачы сүгенеп, шушы ук алгоритмны яңабаштан кабатлый иде.

Отыры караңгы төште.

Күзне элпә каплады. Моңарчы төгәл чик буенча бүленгән күк белән җир бербөтенгә әйләнде: җирне – күктән, күкне җирдән аерып булмый башлады. Офык югалды. Чиксез бушлык өстен сыдырып-сыдырып искән җил колакта шаулады. Йөзгә пыяла тузанындай вак һәм үткен кар сипте. Аның үкерүендә әледән-әле урман шаулавын, кыргый этләр улавын яисә үсмер җаныбызның үрсәләнеп үксүен ишетергә мөмкин иде.

Отыры гөлт итеп йолдызлар кабынды. Баш өстендә яңадан күк хасил булды.

Бераздан кемдер җен куәте белән үкчәмә ябышты:

– Син дөрес якка бармыйсың!

– Күтеңне өйрәт!

– Сулга каер!

Баягы тавыш кинәт тынгач кына шуышудан туктарга булдым. Көч-хәл борылып утырдым. Ун-унике метр читтә шәйләнгән тоныкк күләгә, карашын миннән аермыйча, төпсез күккә кизәнде. Аның сулышы ярыйсы ук тигезләнеп өлгергән иде:

– Әнә Тимер Казык йолдызы. Ул һәрвакыт төньякта. Шөн дә Толлының төньягында урнашкан. Димәк, кирегә, әнә Кассиопея йолдызлыгына таба барырга кирәк.

Мин күләгәнең бер өлешен таба алмадым:

– Телефоның кайда соң?

– Моннан егерме-утыз метрда гына. Кирәк булса, барып ал, бүләк итәм. Кызлар, туда-суда. – Ул беркавым дәшми торды. Үйланды, ахры. – Иярмәсәң, бәхил!

Һәм үзенә өр-яңа юл ярып китте.

Мин урынымда утырып калдым.

Чөнки аның тәкъдиме миңа бер дә ошамады.

Нәүмизләнеп өскә бактым. Күк йөзе тулы якты кыйпылчыклар иде. Кайда нәрсә күрде ул? Кайсыларын атады? Боларны ничек аерып бетерергә мөмкин? Исеме буенча гынамы?

Мин кай арада рәхәтлеккә чумуымны аңышып та бетермәдем. Кинәт бөтен сыным буйлап җылылык йөгерде. Күз алдымда утлар биешергә тотынды. Җаным авыр гәүдәмнән купты гүя: үземдә илаһи җиңеллек тоеп, баш өстемдәге йолдызлар арасына талпындым...

Ләкин мине шунда ук сугып төшерделәр.

Ул өстемә ятып гыжылдый иде:

– Бирешәсе түгел! Ишетәсеңме? Бирешергә ярамый! – Тиз генә яңаклап алды. – Беркайчан да бирешергә ярамый! Аңлыйсыңмы? Тор! Тор!..

Авырсынып кына күзләремне ачтым. Авырсынып кына күрсендем:

– Ярый син бар әле, сука.

Без барыбер зур юлга чыгып җиттек.

Бераз чалышканбыз икән. Исәплә бетермәгәнбез: авылны ышыклап утырган тау башына кадәр дә бер-ике чакрым бар иде әле...

Ерак караңгылык эчендә башта тонык кына мотор тавышы ишетелде.

Аннары ул якынайды, ачыкланды.

Мин арка мие белән таныл-тоеп алдым: Кукмарадан Толлыга кайтучы кечке автобус иде бу...

Тилереп кул болгавыбызга карамастан, ПАЗ безне битараф кына узып китте. Аны озатып җибәрүгә Рүзәл чалканлап карга ауды. Һәм соңарган язның иртәләгән басынкы кичендә җемелдәшкән йолдызларга багып:

– Шәп! – дип ихлас күңелдән ләззәтле өн чыгарды.

Минем йөрәк төбендә кинәт теш сызлап куйгандай булды.

Шулвакыт мин дустыма озын гомер теләдем.

Шигърият

Әхәт САФИУЛЛИН

ТИК СОҢЫННАН БЕЛДЕМ

Янып-көеп, бәхетем читтә, диеп
Ташлап киттем сине, авылым.
Тик соңыннан белдем аерылуның
Бөтен нәрсәләрдән авырын.

Саргаерсың сагынып, китмә, диеп,
Таң җилләре өзелеп сорады.
Тик соңыннан үзем шул җилләрне
Төшләремдә күреп еладым.

Моңсу булып, китмә, китмә, диеп,
Кулын сузып калды талларым.
Тик соңыннан күпме эзләсәм дә,
Андыйларны таба алмадым.

Үзәкләрең өзелер, китмә, диеп,
Баш иделәр ап-ак каеннар.
Тик соңыннан белдем: сагышлардан
Көчле булган нинди кайгы бар?..

Китмә инде, түзалмассың, диеп,
Урман бүлде китәр юлымны.
Тик соңыннан белдем: туган яктан
Китмә икән болгап кулыңны...

СЫНАУ

Кешеләрне җил-давыллар сыный,
Кайгы-хәсрәт сыный кешеләрне;
Аягыннан ега йомшакларны,
Көчле итә бары көчлеләрне.

Кешеләрне зур байлыклар сыный,
Зур урыннар сыный кешеләрне;
Азы гына кеше булып кала,
Кеше булып кала көчлеләре.

Кешеләрне аерылулар сыный,
Кавышулар сыный кешеләрне;
Мәхәббәтнең ялкыннары яман,
Көл итми ул бары көчлеләрне.

Кешеләрне кешеләр дә сыный,
Хайваннар да сыный кешеләрне;
...Бик күпләрне аңлап булмый хәзер:
Хайваннармы, әллә кешеләрме?..

БЕТМӘДЕК БЕЗ!

Саллар кебек актык Иделдә без –
Ташладылар башны чабып-кисеп;
Хәтерләтә безгә моны һаман
Гасырлардан килгән җилләр исеп.
Бетмәдек без, юк, юк, бетмәдек без,
Чапсалар да башны, ассалар да!
Таш астыннан шытып чыктык,
Гөлләр булып үстек бакчаларда.

Безнең каннар акты елга булып,
Йөзебезне кара сагыш сарды;
Ирек югалтуның ачы тәме
Мәңгелеккә яра булып калды.
Бетмәдек без, юк, юк, бетмәдек без,
Еллар саен ныгый бардык һаман;
Дога итеп йөрттек «ирек» сүзен,
«Килер, – диеп, –
килер көткән заман!»

Җиңел түгел тик азатлык юлы,
Аккан сулар кебек бормалы ул.
Ирек алу кайчан җиңел булды?
Белми аны тарих, булмады ул!..
Бетмәдек без, юк, юк, бетмәдек без,
Чапсалар да башны, ассалар да!
Ирек өчен үлгәннәрнең җаны
Гөлләр булып үсә бакчаларда.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 **ЯЗЫЛ!** 2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «Ватаным Татарстан» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 – җомга саны
444 сум 54 тиен
гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 – атнага дүрт тапкыр чыга
1051 сум 80 тиен
гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июненә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»

*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

Адрес: Салих Батыев ур., 1 йорт

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

Реклама 18+

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

Сканворд

Кәҗә-... | Тал-... | Фәнни белгеч | Идел буенда ... еллары (1921–1922) | Алшарт | Икмәк | Читәнгә менүче | Мунчада тия | Белән | Жан һәм ... сихәте | «...болай ашкына-сың, йөрәк?» | Сугыш һәм ... ветеран-нары | Агрессив хис | Тупый кош төре | Спорт җиһазы | Мәктәп тактасы язгычы | ...-ТАСС мәгълүмат агентлыгы | Сабакта орлыклар теземе | Миргазиз Укмаси туган авыл | Чалынган малның ... саны | ...-шәһәр | Язучы Радиф ... | «Су буенда ... яна» | «Бедная ...» сериалы | ...-том | Аның ашы кара-кар-шы | Питрәчтә хәрби уен-нар | Билгесез хәреф | Помидор | ten саны татарча | ...юллар телә | Оста очучы | Сәрхуш әмере | ... Акопян | Базда тозлы кыяр савыты | Христиан бәйрәме | Мена сиңа ... | Гадәти түгел, гаҗәп | Шланг борынлы хайван | Мөмкинлек | Электр булганда бар | Элеккере сәлам | H_2O | Вәгъдә | Кошлар кайта туган ... | «Сәлам» лагере баласы | Өстәмә караплы | Микән туганы | ...-егет | Узәк ТВ-канал | Илфак Шиһапов чыгарган газета

Әз-мәз мәзәк

Әгәр хатын-кыз сиңа дәшмичә карап тора икән, яхшылап тыңла.

* * *

– Рәсим, син ике вегетариан кыз арасында утырасың, теләк телә.
– Кыздырган тавык боты ашар идем.

* * *

– Сайла: йә мин, йә футбол!

– Син минем элеккеге хатыным кебек сөйләшәсең.
– Син миңа кадәр өйләнмәгән идең бит?
– Әйе.

* * *

80 яшьлек Голливуд йолдызларына карыйсың да уйлап куясың: шулар арасында гына пенсия яшен арттыралар бугай бездә!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: галим, тирәк, сәбәп, илә, нигә, тыл, ачу, акбур, ара, ядрә, башак, дан, кунак, Настя, икс, ун, томат, ак, сал, ас, мә, сәер, җай, фил, ясак, якка, икән, су, НТВ, Тишек.
Вертикаль: ИТАР, Укмас, ир, ачлык, Амаяк, Әлбәдән, Ләйсән, ис, арт, ант, мәкәрҗә, им, тән, банка, ут, ипи, Анастасия, Гаташ, сәлкеш, әтәч, Раштуа, учак, янкорма.

Беләсең килсә...

1 «Көчле кешеләр» картинасын кем язган?
а) Бакый Урманче;
б) Харис Якупов;
в) Рушан Шәмсетдинов.

2 «Лексус» автомобильләре кайсы брендтан чыккан?
а) «Ниссан»;
б) «Сузуки»;
в) «Тойота».

3 Бу илдә сирень бәхетсезлек чәчәге санала:
а) Англия;
б) Франция;
в) Австрия.

4 Борынгы грек теленнән бу сүз «кәҗә җыры» дип тәрҗемә ителә:
а) драма;
б) трагедия;
в) комедия.

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.а); 4.б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 277

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булarак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+